# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

1/ 2024

*Курчак – мәдәният тарихының иң кызыклы битләреннән берсе. Һәр халыкның бик борынгы заманнардан ук килүче үз уенчыклары бар, алар миллилекне, көнкүрешне, гореф-гадәтләр һәм йолаларны, техник һәм сәнгать казанышларын чагылдыра*



# Хуш киләсең, Нәүрүз!











**Нәүрүз – төрки һәм фарсы телле халыкларның бик борынгыдан килгән бәйрәме. Ул 21 мартта көн белән төн тигезләшкән көнгә туры килә.**

Бу көнне авыл хуҗалыгы белән көн күрүче халыкларның Яңа елы башлана. Фарсы теленнән ул «яңа көн» дип тәрҗемә ителә.

2009 елда Нәүрүз ЮНЕСКО тарафыннан Бөтендөнья матди булмаган мәдәни мирас исемлегенә кертелә, 2010 елгы БМО Генераль Ассамблеясе карары нигезендә рәсми халыкара бәйрәм статусын ала.

Татарстанда яшәүче азәрбайҗан, казакъ, кыргыз, таҗик, үзбәк һәм башка төрки халыклар Нәүрүзне милли йола бәйрәме буларак үткәрәләр. Ул көнне ел буе кылган гамәлләргә нәтиҗә ясала, киләчәккә планнар корыла.

Нәүрүз бәйрәме төрки халыкларны милли-мәдәни берләштерүгә һәм аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертә.

Нәүрүз бәйрәмен татарлар да каршылый. Яңа елны март аенда башлап җибәрүнең татарлар яшәгән Урта Идел буенда булганлыгы мәгълүм. Ул чорда Нәүрүз көннәрендә (ул бер атнага – 10 көнгә сузылган) йорттан-йортка кереп «нәүрүз әйтеп» йөрү гадәте булган. Моны укучы балалар, шәкертләр башкарган. Нәүрүз такмагын укып, яки яттан әйтеп, хуҗаларга бәхет, уңышлар теләп йөргәннәр.

**Фоторәсемнәр Чирмешән һәм Әлки районнары Мәдәният йорты архивыннан**

# ЭЧТӘЛЕК


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **«Гөлханә/Чәчәкләр йорты» күргәзмәсе**

8 **«Мәдәният игелеклелеккә хезмәт итәргә тиеш...»**

10 **Луганск – Татарстан арасындагы мәдәни-иҗади хезмәттәшлек**

**ГАИЛӘ ЕЛЫ**



12 Р. Мөхәммәтова
**Алсу һәм Илдар Хәйруллиннарның тормыш сәхифәләре**

**ЗӘВЫКЛЫЛЫК БЕЗДӘН БАШЛАНА**



20 Г. Измайлова
**«NAIMAN» — гарәпчә «ТЫНЫЧЛЫК» дигән сүз**

**ӘДӘБИ МИРАС**

26 Л. Мөхәммәтҗанова
**Себердә – татар рухы**



**Түгәрәк уен**

№ 1 (51) / 2024


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәнияты өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге



Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов



Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 14.03.2024
Чыгу көне: 26.03.2024
Заказ: 18 Тираж: 1000 экз.



Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru



«Фолиант» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Восстание ур., 100, корп. 6130



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:** Курчаклар коллекциясе. 2021 ел.
Материалы: сарык йоны.
**Ләйлә Низамова** эшләнмәсе


© «Түгәрәк уен», 2024

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ


32 Р. Степанова
**«Гаиләм – илһам чишмәсе»**
*(Сценарий)*




МИЛЛИ УЕННАР




40 Ф. Хәнәфиева
**Милли уеннар – халкым мирасы**


БЕЗГӘ ЯЗАЛАР




42 Г. Хәкимуллина
**Гатаулла бай йорты – Әтнәнең символы**

45 Л. Хәкимова
**Милли мирас өләшүче «Хәзинә»**


МИФОЛОГИК МИРАС


34 Г. Гыйльманов
**Фаллар**


БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ





48 **Фольклористикада – халык әкиятләре**


БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...




52 Э. Сәйфуллина
**«Максатым – Самара татарлары фольклорын, халкыбызның борынгы киемнәрен, уен коралларын, җыр-такмакларын таныту»**

57 **Язбикә**
*(Җыр)*


ӨЙ КҮРКЕ – АШ




58 **Кыстыбый**


ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ


62 **Бергәләп бизибез!**

# «Гөлханә/ Чәчәкләр йорты» күргәзмәсе

**Быелның 13 гыйнварыннан 11 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли галереясында Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Баки Урманче исемендәге Премия лауреаты Луиза Фәсхетдинованың күргәзмәсе үтте.**





«Миннән, бу күргәзмәнең төп казанышы дип нәрсәне санарга кирәк, дип сорадылар. Күргәзмәнең төп казанышы – һичсүзсез, Луиза Фәһим кызы үзе. Һәм ул бу күргәзмәнең генә түгел, бөтен республиканың казанышы. Ул – республикабызда бер кул бармаклары белән генә санарлык сирәк очрый торган осталарның берсе. Мин аны ачык йөзле, изге күңелле кеше һәм, билгеле, югары дәрәҗәдәге профессионал буларак беләм», – диде, авторны күргәзмәсе ачылуы белән котлаганда, Татарстан Мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин.

Луиза Фәсхетдинованың иҗади эшчәнлеге татарларның













укалап чигү һәм чигү сәнгате традицияләрен кабат торгызу һәм үстерү белән бәйләнгән. Ул милли киемнәр комплексына кергән эшләнмәләрдә (күлмәкләр, камзуллар, калфаклар, түбәтәйләр һәм башкалар), гореф-гадәт, йола һәм көнкүреш предметларында (сөлгеләр), татар мәдәниятенең дини-рухи символлары булып торучы әйберләрдә (шәмаилләр, намазлыклар һәм күп кенә башка предметлар) традицион чигү һәм укалап чигү үрнәкләрен уңышлы файдалана.

Луиза Фәсхетдинованың иҗаты Халыкара (Төркия, Пакыстан, Ирак, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Германия, Венгрия, Франция, Бөтенроссия), төбәк һәм республика күргәзмәләрендә тәкъдим ителде. Алар Татарстан һәм Россия музейларында һәм чит илләрнең шәхси коллекцияләрендә саклана.

Үзенең бөтен иҗади эшчәнлеге дәвамында Луиза Фәсхетдинова Иранда, Төркиядә,





Үзбәкстанда уздырылган эре Халыкара фестивальләрдә, һәм шулай ук Бөтенроссия күргәзмәләрендә «Уникаль Россия», «Россиянең чигелгән картасы», «Федераль Сабантуй» һәм башка эшләре белән Татарстан Республикасы данын яклап килде.

Күргәзмәдә рәссамның соңгы биш ел эчендә иҗат ителгән 30дан артык эше тәкъдим ителде. Болар – дини йолалар башкару өчен ачык төстәге бизәкләр кулланып чигелгән әйберләр – намазлыклар, шәмаилләр, Коръән тышлыклары һәм япмалары. Шулай ук традицион татар киемнәренең яңартылган үрнәкләре, Казан татарларының (ирләрнең һәм хатын-кызларның) бик матур чигеш белән бизәлгән баш киемнәре күрсәтелде.

«Гөлханә/Чәчәкләр йорты» күргәзмәсе Луиза Фәсхетдинованың юбилеена туры китереп тәкъдим ителде – оста ханым аны Яңа ел алдыннан – 31 декабрьдә билгеләп үтте. Вернисажның бик күп кунаклары арасында Төркиянең Казандагы илчесе Уйгур Йылмаз һәм Казахстанның генераль илчесе Ерлан Искаков та бар иде.

*Быелның 3 мартында Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында узган «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә «Хатын-кыз – мәдәни һәм рухи өлкәдә» номинациясендә Луиза Фәсхетдинова җиңү яулады. Котлыйбыз!*

Фоторәсемнәр izo-museum.ru сайтыннан алынды, В. Крылов фоторәсемнәре







# «Мәдәният игелеклелеккә хезмәт итәргә тиеш...»

**Бу елның гыйнвар азагында Мәскәүнең Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендәге (ВДНХ) «Россия» Халыкара күргәзмә-форумы кысаларында Мәдәният көне уздырылды.**

Ул Россия Федерациясе мәдәният министры Ольга Любимова катнашында «Мәдәният: киләчәккә инвестиция» пленар сессиясе белән ачылды. Сессиядә Татарстан Республикасы мәдәният министры Ирада Әюпова җитәкчелегендә Татарстан мәдәният министрлыгы делегациясе дә катнашты.






ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле солистлары күргәзмә кунаклары өчен халык биюләре буенча мастер-класс уздырды, һәм шулай ук мәйданчыкта Казанның халык сәнгате һөнәрләре техникумы вәкилләре – тире мозаикасы, Н.И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы вәкилләре татар милли бизәкләре төшерелгән открыткалар җитештерү буенча мастер-класслар үткәрде, танылган татар драматургы Кәрим Тинчуринның «Сүнмәс йолдызлар» спектакленнән өзек күрсәтелде.








«Безнең милли тәңгәллекне ныгыту өчен мәгариф һәм мәдәният гаять әһәмиятле. Мәдәният игелеклелеккә, матурлыкка, үзара яраклашуга хезмәт итәргә, иң яхшы кешелек сыйфатларын үстерүдә ярдәм итәргә тиеш», – диде Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин.








# Луганск – Татарстан арасындагы мәдәни-иҗади хезмәттәшлек

**2024 елның 19-20 февраль көннәрендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының министр урынбасары Ленар Хәкимҗанов, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурсы үзәге директоры Алсу Мифтахова, Казанның 2нче балалар сәнгать мәктәбе директоры Евгений Кубышкин һәм башка мәдәният учреждениеләре вәкилләре составындагы делегация Луганск Халык Республикасының мәдәният учреждениеләренә методик ярдәм күрсәтүдә катнашты.**



Татарстан Республикасы делегациясен Луганск халык иҗаты үзәге директоры, Украинаның атказанган мәдәният хезмәткәре Василий Яровой кайнар сәламләде һәм әлеге вакыйганың Луганск Халык Республикасы һәм Татарстан Республикасы арасындагы мәдәни элемтәләрне үстерү һәм ныгыту өчен зур әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте. Әлеге чара барышында Алсу Мифтахова үзәк хезмәткәрләрен, презентацияләр күрсәтеп, Татарстан Республикасының мәдәни-ял итү учреждениеләре эше белән таныштырды, шулай ук алга таба уңышлы хезмәттәшлек итү өчен аеруча мөһим булган чараларны билгеләп үтте.

Луганск халык иҗаты үзәге эше белән таныштыру максатыннан, директор урынбасары, Луганск Халык Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Ирина Яворская кунаклар өчен үзәк буйлап экскурсия оештырды, Луганщинадагы мәдәниятнең формалашуы һәм үсүе тарихы турында сөйләде.

Луганск Халык Республикасының «Луганск Халык иҗаты үзәге» Дәүләт мәдәният бюджет учреждениесе белән «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул кую әлеге чараның кульминацион ноктасы булды.

Делегациянең М. Матусовский исемендәге Луганск мәдәният һәм сәнгать дәүләт академиясе белән танышу программасы кысаларында Луганск балалар сәнгать мәктәпләре җитәкчеләре белән гамәли семинар үткәрелде.

Очрашу вакытында Татарстан вәкилләре коллегаларына бүләкләр – методик һәм укыту материаллары тапшырды. Шулай ук һәр ике як Бөтенроссия фестивальләре, төбәкара семинарлар һәм мастер-класслар проектларын тормышка ашыру кысаларындагы уртак чаралар турында фикер алышты. Соңыннан М. Матусовский исемендәге Луганск мәдәният һәм сәнгать дәүләт академиясе һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурсы үзәге арасындагы хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшү турындагы килешүгә кул куелды.

Шулай ук балалар интернат-мәктәбе җитәкчеләре белән методик очрашулар оештырылды, музейара хезмәттәшлек мәсьәләләре тикшерелде. Луганск өлкәсе крайны өйрәнү музее экспозициясе белән таныштыру максатыннан музейның ядкәрләрне саклау бүлеге хезмәткәре Тимур Хәкимов кунаклар өчен экскурсия оештырды.

Татарстан делегациясе Антрацит шәһәрендә «Чишмә» татар-башкорт мәдәни үзәге җитәкчесе Гөлфия Кәбирова белән очрашуда һәм татар китаплары һәм сувенирлары тапшыруда катнашты.

Шул ук көнне Антрацит шәһәрендә Луганскидагы татар җәмгыяте өчен Татарстанның А. Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт фольклор ансамбле чыгыш ясады. Икенче концерт Молодогвардейск тамашачылары өчен булды.






Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# АЛСУ ҺӘМ ИЛДАР ХӘЙРУЛЛИННАРНЫҢ ТОРМЫШ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Рузилә МӨХӘММӘТОВА,*
*журналист*

**Быел татар театры династияләренең берсе – Хәйруллиннар өчен юбилейлар елы. Беренчедән, легендар актриса – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Россия дәүләт премиясе һәм Татарстанның Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты Алсу Гайнуллинаның түгәрәк юбилее. Икенчедән, Илдар Хәйруллин белән Алсу Гайнуллинаның никахларына быел 50 ел булды.**

«Нәкъ 50 ел элек Марсель Сәлимҗановның әти-әнисе театрда алтын туй үткәрделәр – без ул туйда булдык. Без дә шулай яши алырбызмы икән дип көлешеп утырдык. Быел безнең 9 февраль көнне бергә яшәгәнебезгә 50 ел булды. 50 еллыкны туганнар белән генә уздырабыз, Алсу шау-шуны яратмый. «Мин уйныйсын уйнаган, аласы исемнәрне алган, миңа нәрсәгә, ди. Кәнәфигә утырып үзен мактаганны тыңлап тора торган кешемени ул?», – ди Илдар Хәйруллин бу матур датаны искә алып.

«Түгәрәк уен» журналы Гаилә елын, күпсанлы сораулар буенча, шушы гаиләдән башлады. Татарстанның халык һәм Россиянең атказанган



Кечкенә Илдар әти-әнисе белән



*“Язмышка рәхмәт: күрештек тә ничектер үзеннән үзе бер-беребезгә якын булып киттек. Бер-беребездән аерыласы килмичә өйләнештек.”*



Алсу Гайнуллина һәм Илдар Хәйруллин

артисты Илдар Хәйруллин тормыш сәхифәләренең кайбер битләрен актарырга ризалык бирде.

*– Илдар абый, татар гаиләсенең әдәби-театраль стандартлары – ир эштән кайта, хатыны токмачлы аш пешереп каршы ала. Ике артист гаиләсендә мондый идиллия була аламы?*

– Ул махсус эшләнә торган әйбер түгел. Ике кешенең үзара мөнәсәбәтләренә бәйле. Алсу гаиләдә тугызынчы бала. Әти-әнисе бик әукатьле, әдәпле кешеләр иде. Әнисе гомере буе намазда булган зирәк, акыллы хатын иде. Алсуны да шулай тәрбияләгәннәр дисәм, тәрбия дә түгел, шулай канына салынган. Алсу бик акыллы, тыныч, ул күпне күрми, күпне ишетми, күп әйбергә исе китми. Алсу училищеда укый иде, мин яшь артист. Язмышка рәхмәт: күрештек тә ничектер үзеннән үзе бер-беребезгә якын булып киттек. Бер-беребездән аерыласы килмичә өйләнештек. Гомер буе, Аллага шөкер, әйткәнем булмасын, матур яшибез. Мин үзем кызып китүчән, эмоциягә бирелеп авыр сүз әйтүем дә мөмкин. Алсу киресенчә бик сабыр, көлеп кенә карый. Яшь вакытта салгалап та аласың, бөтен җәмгыяте шундый иде. Бер сүз әйткәне булмады. Ашатып-эчертеп яткыра иде. Без гомер буе бер-беребезнең кадерен белеп яшәдек. Һавада очып йөрмәдек. Әйе, башта йөрешкәндә бар иде ул әйбер – очып йөрүләр. Аннары табигый булып китте. Сөбханалла, 50 ел матур яшәдек.

*– Алсу апаның мактаулы исемнәре күбрәк...*

– ...Таланты да зуррак.

*– Татар ирендә хатын миннән уздырмасын дигән әйбер бар кебек...*

– Юк. Абсолютно юк. Мин аның белән горурланам гына. Аллага шөкер дип торам. «Кара чикмән»дә премьераны карап утырганымны хәтерлим. Шаккаткыч иде бит. Икенче мисал – «41нең арбалы хатыннары». Премьерада утырам. Актриса чыгып уйный башлады. 5 секунд узды, 10 секунд узды... мин танымыйм. Ә бит анда грим салынмаган. Мин Алсуны танымадым. Менә нинди актриса булырга тиеш! Сокланам гына мин аңа! Караган саен сокланам.

*– Аның талантыннан яшь чагында да көнләшмәдегезме?*

– Юк... Кайчакта көлешеп сөйләшәбез. «Мин эләкмәсәм», – дип әйтеп куя да, мин әйтәм: «Биш-алты хатын алыштырыр идем. Минем характер белән яшәп булмый», – дим. Гаиләне Алсуның сабырлыгы, аның зирәклеге, тынычлыгы саклап килә. Бер-беребезне без бик сагынышабыз. Хәзер бигрәк тә. Кешеләрнең бит рухи яктан гына түгел, ниндидер химик бәйләнеше дә бар. Хәтта ис тә туры килергә тиеш. Монда ничектер безнең бар яктан туры килгән, Аллага шөкер!

Кешене яратканда, миңа моннан нинди яхшылык булыр икән, дип карамыйсың. Кешене яратасың икән, мин ул кешегә нәрсә бирә алам, дип уйлыйсың. Без икебез дә шушы бер фикердә яшәдек, Аллага шөкер, мин бу кешегә нәрсә бирә алам дип уйладык. Алсуның да шулай әйткәне бар.

Хатын аерып, тагын өйләнеп, бәхетле булган кешеләр бик сирәк. «Первая жена от бога, вторая от народа, третья от черта» дигән сүз бар. Алла биргән шул бер хатын белән яшәлгән, Аллага шөкер! Алсу бик чиста, пакъ, күптән намазда, ике тапкыр Хаҗга барып кайтты.

*– Кеше Хаҗга барса, дөньяны кубара, бөтен җирдә фотосы, сүзе. Алсу апаның барып кайтканын да ишетмәдек.*

– Алсу шаулап йөрми.

*– Бер генә бала белән калдык дигән үкенеч юкмы?*

– Анысы булды инде. Искәндәргә 4 яшендә минем әни үлде, аның икенче этидән туган ике



Алсу Гайнуллина һәм Илдар, Искәндәр Хәйруллиннар

> *Гаиләне Алсуның сабырлыгы, аның зирәклеге, тынычлыгы саклап килә. Бер-беребезне без бик сагынышабыз. Хәзер бигрәк тә. Кешеләрнең бит рухи яктан гына түгел, ниндидер химик бәйләнеше дә бар.*



Улы Искәндәр, килене Айгөл һәм Алсу Гайнуллина



«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакленнән (Т. Миңнуллин)

баласы калды. Берсенә – 8, берсенә 12 яшь иде, кыз белән малай. Аларны без тәрбияләргә опекунлыкка алдык. Алсу үзе дә бала гына иде, ул өч баланы карады. Мәскәүгә гастрольгә барсак, беренче аларга кием ала иде, үзебезгә, улыбызга түгел. Бик карадык. Аллага шөкер, аякка бастырдык. Хәзер инде алар да олыгаеп килә.

*– Гаиләдә ир белән хатынның бер темага төрле карашлары булырга мөмкин. Көнкүреш темасын күздә тотмыйм, фәлсәфи, җәмгыяви, сәяси темаларга, мәсәлән. Андый очракта гаиләдә ничек аңлашасыз?*

– Әйтешү булырга мөмкин. Тормыш булгач барысы да була. Ләббәйкә белән генә булмый. Мин үз карашларымны яклыйм, Алсу үзенекен...

*– Кем юл бирә?*

– Көлешәбез дә бер фикергә киләбез.

*– Илдар абый, сез гомерегез буе артистлар тәрбияләдегез. Искәндәр дә артист, ләкин сездә укымаган. Өйдә генә булса да, аның өчен күпмедер дәрәҗәдә педагог була алдыгызмы?*

– Мин үзем рәсми рәвештә укытмаган кешеләргә тыгылмыйм. Яшь артистларга тегеләй эшлә, болай эшлә дип киңәш тә бирмим. Ул профессиональ этикага сыймый. Аның укытучысы бар, аның режиссеры бар. Бөтен нәрсәне аларга әйтергә кирәк, актерга әйтергә ярамый. Бу башны бутау гына. Ә Искәндәргә бигрәк тә.

*– Артистның ялгышы өчен укытучы җавап бирәме?*

– Режиссер. Педагог укытып чыгарган бит инде. Мин курсны чыгарганда һәрвакыт әйтәм: зур рольләр дип кызыкмагыз, сезгә ышанган, сезне яраткан, синдә актер күргән үз режиссерыгызны табу мөһим дим. Режиссер белән актер бер берсен яратса, шунда иҗат була, шунда канәгать буласың.



«Сәяркә» спектакленнән (Т. Миңнуллин)

*– Искәндәр театр юлын сайлыйм дигәч, «юк» димәдегезме?*

– Юк. Марсель Сәлимҗанов белән Фәрит Бикчәнтәев институт өчен беренче курс җыя башлаганда Искәндәр шунда кергән дә аны бик яратканнар. Мәктәпне тәмамламаган бит әле – аның өчен махсус «свободное посещение» ясадылар да, мәктәпне укып бетергәч, өстәмә набор белән кабул иттеләр. Ул бит өлгергән актер. Өйдә вак-төяк буенча нидер әйткәли башласам: «Әти, мин кырыктан уздым бит инде», – ди. «Галиябану» пьесасында бит кырыклардагы кеше авыл карты дип язылган...

*– Сезнең киленегез Айгөл Миңнуллина Туфан абый Миңнуллин белән бер нәселдән, туганнан туганы бит, әйеме?*

– Энесенең кызы.

*– Алар өйләнешкәндә Туфан абый исән иде. Кодалар булып йөрдегезме?*

– Әйе. Әле шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов: «Тормышың түгәрәкләнде, Туфан белән дә кодалаштың», дип, эпиграмма да язган иде.



«Өч сеңел» спектакленнән (А. Чехов)

> *Мин курсны чыгарганда һәрвакыт әйтәм: зур рольләр дип кызыкмагыз, сезгә ышанган, сезне яраткан, синдә актер күргән үз режиссерыгызны табу мөһим дим. Режиссер белән актер бер берсен яратса, шунда иҗат була, шунда канәгать буласың.*

*– «Килен каенана туфрагыннан ярала», диләр. Киленегез Айгөл кайсыдыр яклары белән Алсу апага охшаганмы?*

– Күзәтмим. Мин яшьләрне күрмәскә тырышам. Баштан ук шулай куйдым – «Кысылмыйбыз, тормышыгызны күзәтмибез», – дидем. Менә бер мисал – туганнарыбыз уллары белән бергә яшәде, улы өйләнгәч, яшьләр фатир арендалап аерым яши башладылар. Коттедж төзергә тотындылар, кергән акча шунда китә. Фатирга түләп ятмагыз, үзебез белән яшәгез дип яшьләрне кайтардылар. Ду килделәр, аралары бозылды. Табаны кем болай юа, нигә бу әйберне монда куясың... бик катыга киткәч, тегеләр яңадан фатирга чыгып киттеләр. Тагын искитмәле яши башладылар. Ике гаилә бер-берсеннән ял итәргә тиеш. Яшьләрнең үз тормышы, үз гадәтләре... Алсу белән без икебез дә шулай дип уйлыйбыз. Кунакка гына киләләр.

*– Илдар абый, Искәндәргә «татар кызы ал» дип әйтеп үстердегезме?*

– Без аны әдәпле үстерергә тырыштык. Тәртип бозма, Аллаһтан курык, милли үзаң булсын дип, кечкенәдән тәрбияләдек. Алсу көлә инде: «Син булмасаң, Искәндәр русча сөйләшер иде», – ди. Өйдә татарча сөйләшү тәртибе иде.



**«Әрем исе» спектакленнән (И. Зәйниев)**

*– Әйтеп тордыгызмы?*

– Русча дәшсә, «Улым, аңламыйм бит русча», – дип кенә әйттем. Көлә иде. Аңлый инде аңлаганымны, шулай да татарчага күчә. Хәзер урамда русча белмәгән әбинең оныгы белән ят телдә сөйләшүен күреп күңелем рәнҗи. «Зачим туда пашол. Иди сюда», – дип, телен вата-җимерә оныгы белән русча сөйләшә.

*– Сез оныклар белән татарча аралашасызмы? Зурмы инде алар?*

– Алар белән дә татарча сөйләшәм. Искәндәрнең ике бала – Аяз, Зәйнәп. Берсенә – 14, икенчесенә 10 яшь. Оныкларны кунак итәбез. Тәмле ашатабыз. Хәзерге балалар без караган мультфильмнарны да карамыйлар. Мин яраткан «Ну погоди», «Серая шейка» аларга кызык түгел.

*– Хәйруллиннардан дүрт кешенең бер театрда булуы уңайсызлык тудырмыймы, бәлки, киресенчә – бер-берегезне карап, саклап торасыздыр.*

– Искәндәрнең үз фикере, үз карашы. Бервакыт, әле Искәндәр өйләнмәгән иде, Туфан абый пьеса укырга килде. «Саташу» дигән пьесасы бар иде аның. Анда кыз бала әти-әнисен судка бирә. Туфан абый аны беренче булып безгә алып килгән иде. Коллектив фикер әйтергә тиеш. Бөтенесе уңайсызланалар, начар тема, пьеса ошамый. «Сүз әйтегез», – дигәч, Искәндәр торды да: «Туфан абый, болай булмый бит инде», – дип, җитешсезлекләрен санап чыкты. Туфан абый бик үпкәләде, кайтып китте, театрга бер-ике ай килмәде. Кемдер очраткан да: «Туфан абый, театрда күренмисең», – дигән. «Бармыйм мин анда, барсам, Илдар малае мине пьеса язарга өйрәтә», – дигән.

*– Бер гаилә кешеләре белән бер сәхнәдә уйнау кыенмы?*

– Анысы бик кыен. Профессиональ яктан карап, күрмәскә, сизмәскә тырышасың инде. «Сөяркә»дә (Туфан Миңнуллин пьесасы буенча куелган) Фирдәвес Хәйруллина белән дә, Алсу белән дә уйнадым. Алсу белән уйнаганда беренче күренешләрдә бераз киеренкелек була иде дә, аннары ачылып китәсең. Аның хатыным икәнлеге дә онытыла. Эмоцияләр генә кала.

*– Ә Искәндәр белән?*

– Шулай ук авыр. Лопе де Веганың «Бию-че»сендә, «Өйләнәм»дә (Илгиз Зәйниев пьесасы буенча куелган) бергә уйнадык. «Өйләнәм»нең финал күренешләрендә Искәндәр белән талашабыз әле. Кыен бергә уйныйсы.

*– Театр темасы өйгә дә ияреп кайтамы?*



**«Хуҗа Насретдин» спектакленнән (Н. Исәнбәт, С. Ваннус)**

– Юк. Өйдә сәнгать турында сөйләшмәскә тырышабыз. Ниндидер табу́ ул. Эштәге уйларны эштә калдырып кайтабыз. Алсу да, Искәндәр дә кеше сүзе тыңлап, сөйләп йөри торган кешеләр түгел. Мәсәлән, мин театрда булмаган көнне Алсу эштән кайткач: «Нинди яңалыклар?» – дип сорасам «Белмим. Үзең барып кара инде», – ди. Искәндәрдән: «Нинди яңалыклар?» – дип сорасам, ул да: «Әй, белмим инде», – ди. Алар икесе дә кеше күзәтеп йөрми. Аллага шөкер, бездә андый әйберләр юк.

– *Рольсез торган вакытларда бер-берегезне ничек юатасыз?*

– Булды инде андый чаклар. Күп булды. Мин үзем тик тормыйм. Укытырга чабам, юбилей кичәләре эшлим. Иң кызыгы берьюлы өч концерт әзерләү – Камалда, филармониядә һәм берәр ДКда. Берсе юбилей, берсе иҗат кичәсе, берсе солянка концерты булырга мөмкин. Ну анда адреналин! Хәзер юбилейларга бик акча бирми башлагач, болар кысылды инде. Эш булмаганда мин борчыла башлыйм.

– *Берәр хоббиегыз бардыр бит?*

– Хобби дип, эш тә, театр инде. Казанда көн саен спортзалга барам. Бассейнга. Безгә негатив күп җыела. Күз тия. Су шул негативтан арындыра. Буш вакытта пьесалар укыйм. Элек китаплар күп укый идем. Гомер-гомергә укыдым...

– *Ә хәзер? Укырлык китап юкмы?*

– Әйе, бөтенләй юк. Бар дигән булалар, иҗат итәбез диләр. Һаман да колхозлаштыру елларын язалар. Туксанынчы елларда Зөлфәт Хәким «Курку» повестен чыгарды. О-о-о бер утыруда укылды...

– *Депрессиядән ничек чыгасыз?*

– Ялгыз калу – иң әйбәт тынычлану юлы. Безнең авылда йортыбыз бар. Шунда китеп тынычланабыз. Өйләнгәнче Искәндәрнең дә: «Мине шунда илтеп куй әле», – дигәне булды, шунда ялгызы гына 4-5 көн ятты. Урманда йөри, ял итә. Мин дә арый башлавымны сизүгә авылга китәм.

– *Анда нишлисез?*

– Тәрәзәдән карап утырам. Элек җәй көне гөмбәгә, җиләккә дә йөри идек. Хәзер кабаннар күбәйгәч, куркыта башлады. Алсу әле апасы белән бер атна авылда яшәп килде...

– *Рәхмәт, Илдар абый!*

*Хәйруллиннар гаиләсенә күз тимәслек итеп кенә сөйләштек. Озак еллар иҗат итәргә язсын һәммәгезгә дә!*

Фоторәсемнәр И. Хәйруллинның шәхси һәм
Г. Камал театры архивыннан

# «NAIMAN» – ГАРӘПЧӘ «ТЫНЫЧЛЫК» ДИГӘН СҮЗ

*Галия ИЗМАЙЛОВА,*
*«NAIMAN» брендын төзүче*






**«Милләт» сүзенең күп төрле билгеләмәләре арасында бөек француз тарихчысы Эрнст Ренан аңлатмасы безгә күпкә якынрак. Милләт дип ул территориаль сыйфатлары, телләре һәм диннәре уртак булганнарны гына түгел, иң беренче чиратта «үзләренең мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен күмәк саклау теләге булган» кешеләр берләшмәсен исәпләгән.**

Философ Николай Бердяев бу идеяне эләктереп алган һәм алга таба үстергән: әйе, үз мәдәниятләре; әйе, уртак гореф-гадәтләр; әмма аларны аерым бер уйдырма хикәятләр һәм символлар ярдәмендә тудыралар. Һәм бу «уртак иҗат ителгән хикәятләр»не кием-салым мисалында ачыграк күрергә мөмкин. Бер яктан караганда, болар – бик файдалы әйберләр. Икенчедән – мәдәниятнең нечкәлекләрен билгеләүче символлар.




L FESTIVAL
CRAFTS
2023


L FESTIVAL
CRAFTS
2023





## ХЫЯЛ

Балачагымнан ук мин кием дизайны турында уйлана идем, төрле образларны, стиль коллаборациясен, тукыманың төсен һәм рәсемен үзара яраштырырга тырышуымны хәтерлим.

Балачак хыялымны 2023 елда билгеле бер стильдәге кием сайлауның катлаулы булуын аңлагач исемә төшердем. Сыйфатлы, әмма шул ук вакытта уңайлы, чын тукымадан тегелгән күлмәк һәм итәкләр кияргә теләвемне аңладым. Шуннан соң Галактионов урамындагы кибеттән Италиядән кайтартылган ефәк тукыма сатып алып, ательеда берничә күлмәккә заказ бирдем. Бу очраклы хәл генә иде, шулай да дус кызларым үзләренә дә нәкъ шундый ук күлмәкләр тектерүемне үтенделәр. «NAIMAN» бренды тарихы шулай башланды.

Мин үз брендымны ачу һәм уңайлы, нәфис кием-салым җитештерү белән шөгыльләнергә булдым. Бу гади мавыгу гына түгел иде. Хәзер бөтен буш вакытымны шул эшкә багышлыйм, ул – илһамландыручым.




Милли, мөселман киемнәре дизайны турында күбрәк белү өчен, кием-салым күргәзмәләренә, фестивальләренә, этнографик музейларга, галереяларга бик кызыксынып йөрдем, дөньяның төрле илләрендә яшәүче кием дизайнчылары белән таныштым һәм аралаштым. Күргәннәремнән илһам алып, стильгә, дизайнга, матурлыкка өстәмә идеяләр уйлап таптым һәм үз эскизларымны, үз сурәтләремне булдырдым. Шул ук вакытта ата-бабаларыбызның мәдәни символларын һәм гореф-гадәтләрен, Ислам кануннарын чагылдырырга тырыштым. Бүген бөтендөнья модасының төп сүзе – «мирас».



## БРЕНДНЫҢ ИСЕМЕ

«NAIMAN» – гарәпчә «ТЫНЫЧЛЫК» дигән сүз. Ул брендның төп фикерен дә символлаштыра – кешеләрне үзара берләштерү, идеяләр алмашу өчен җәмгыять вәкилләре, һәм шулай ук илләр, мәдәниятләр арасындагы элемтәләрне җайга салу һәм шуның белән кешелекне алга өндәү. Чынлыкта бу бөтен дөньяда югары дәрәҗәдәге тынычлык урнаштыру идеясе – бар халыкның татулыгы һәм рухи бердәмлеге.

Найман стилендәге кыз – киләчәккә омтылучан, эшлекле, назлы, матур; ул хәзерге үзгәреп торучан дөнья белән бер адымда атлый, шул ук вакытта Ислам һәм үз халкы традицияләрен хәтерендә тота һәм хөрмәт итә.

*Бүген бөтендөнья модасының төп сүзе – «мирас»*





## МОДАЛАР КҮРСӘТҮДӘ КАТНАШУ

«NAIMAN» бренды 2023 елның 15-23 июлендә Болгар шәһәрендә уздырылган «Яңарыш: Эпосның заманча укылышы» фестивале программасына кергән III «Тормыш стиле – мәдәни код» фестивалендә катнашты.

2023 елның 21-23 сентябрендә Кокан шәһәрендә (Үзбәкстан) уздырылган II Халыкара халык-гамәли сәнгате фестивалендә «NAIMAN» бренды дөньяның 78 иле арасында Татарстан данын яклады.

Әлеге чараларны үткәрүдә ярдәм иткән өчен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, һәм шулай ук Татарстан мәдәни ресурслар үзәгенә рәхмәтемне белдерәм.

## БРЕНДНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ

Бүген минем сатып алучыларым – Казанда яшәүче хатын-кызлар, ниятем – Бөтендөнья дәрәҗәсенә чыгу; дөньяның төрле илләре урамнарында үзебезнең милли киемнәрдән йөргәндә, мин, горурланып, бу образларның Татарстан Республикасында тудырылуын әйтергә теләр идем.

Бүген брендны тәкъдим итүнең төп каналлары – социаль челтәрләр, алга таба интернет-кибетләр төзергә һәм социаль челтәрләрдә реклама компанияләрен эшләтеп җибәрергә, шулай ук модалар тәкъдим итү чараларында һәм күргәзмәләрдә катнашырга ниятлим.

Мин «NAIMAN» брендының киләчәгенә, нәфислек, зәвыклылык һәм уңайлылыкны бәяли белүчеләр өчен тудырылган, үзенчәлекле эстетика белән сугарылган киемнең уңыш казануына ышанам. Чөнки югары дәрәҗәдәге сыйфатка ия булган кабатланмас стиль – үзен хөрмәт итүче кешенең индивидуальлеге гәүдәләнеше ул.

## БЕРЕНЧЕ КОЛЛЕКЦИЯМ

Үз коллекциямне төзергә мине борынгы бабаларыбызның мәдәни кодлары, һәм шулай ук татар халкының Ислам кануннарын чагылдырган милли традицияләре илһамландырды.

Минем образларымда мөселман стиленең бүгенгенең индивидуальлеген һәм кабатланмаслыгын ассызыклаучы үткәне, хәзергесе һәм киләчәге үзара бергә үрелгән.

Коллекция бүгенге заман хатын-кызлары өчен төзелгән, ул традицияләр, эко-стиль, уңайлылык һәм матурлык күренешләрен үзенә сеңдергән. Матурлык һәм уңайлылыктан тыш, бер киемне – эшлекле очрашуларда да, офистагы гадәти эш көнендә дә, икенчесен театрларга, күргәзмәләргә барганда, бәйрәм чараларында катнашканда кияргә мөмкин булсын өчен, мин күпмедер дәрәҗәдә универсальлектән дә файдаландым.

Фоторәсемнәр Г. Измайлованың шәхси архивыннан

# СЕБЕРДӘ – ТАТАР РУХЫ

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының*
*баш фәнни хезмәткәре*



## КАЗАННАН – КАЗАНЛЫГА

Себер җирлегендә яшәүче татарлар тарихи яктан төрле этник компонентлар кушылмасыннан гыйбарәт. Биредә борын-борыннан көн күрүче җирле халык, XIV гасырлардан бирегә күпләп агылган бохаралылар (ягъни Урта Азия төркиләре), төрле чорларда Идел буеннан күченеп килгән татарлар һәм башкалар бүгенге көндә халкыбызның үзенчәлекле бер катламын тәшкил итеп яшиләр. Шуңа күрә Себердә яшәүче татарларның рухи культурасы, аерым алганда фольклоры гаять кызыклы, бай, төрле яклап өйрәнүне сорап тора.

Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырган фәнни экспедицияләрдә гадәттә халыкның барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән эпик һәм шигъри сүзе, бәйрәмнәре, йола-гадәтләре, халык медицинасы, педагогикасы, милли сәнгатебез үрнәкләре, музыкасы, бәйләү-чигү осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп өйрәнелә. Мондый чараның төп нәтиҗәсе – халыкта булган матди һәм рухи хәзинәләрне күреп алып, аларны бөртекләп җыйнау, реконструкцияләү һәм халыкның үзенә кире кайтару. Себернең Омск, Новосибирск, Томск һәм башка өлкәләренә комплекслы фәнни экспедицияләр бүген даими оештырыла. Төмән өлкәсе Вагай районына берничә ел элек уздырылган махсус фольклор экспедициясенең максаты итеп, биредә сүз сәнгате буларак, нәкъ менә фольклорның бүгенге хәлен-торышын барлау мәсьәләсе куелган иде.

## СЕБЕРДӘГЕ АСТАНАЛАР

Казанлы авылына килеп төшкәч тә башкарган иң тәүге эшебез бу авылның астанасы белән танышу булды. Астана – изгеләр зираты. (Астанә – фарсы сүзе, «бусага», «сарай ишеге төбе», «төп» дигән мәгънәләрне белдерә. – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. – Казан, 1965. – Б.19). Биредә шундый исем белән аталып йөртелә торган берничә урын бар дип сөйлиләр. Берничә гасыр элек Себергә

бохаралылар, ягъни Урта Азия төркиләре күпләп агылган. Аларның бирегә килүенең төп сәбәбе сәүдә-икътисад мәсьәләләре булса, биредә ислам динен таратуда да шул ук бохаралыларның роле зур.

Бохаралылар, бу җирләргә килеп төшкәч, төпләнер урын эзләгәннәр. Җирне казыйлар да, чыккан туфракны казылган чокырга кабат күмеп карыйлар икән. Уңдырышлы җирнең туфрагы күпереп, өелеп калырга тиеш булган. Моңа кадәр шундый урын табылмаган, ә Казанлыда исә туфрак казылган чокырына сыймаган, мул булып артып калган. «Уңдырышлы җирләр бу», – дип, изгеләр шушында төпләнеп яши башлаганнар (информант – Казанлы авылыннан Мөнирә Хәлим кызы Сәгыйдуллина (1970 елгы)).

Һәрбер астананың үзенең җаваплы кешесе була. Аны «астана хуҗасы» яисә «астана» дип йөртәләр. Бу кеше изгеләр зиратын карап-тәрбияләп тора, яисә шул эшне оештыра. Астана хуҗасы булу – гади генә йөкләмә түгел, ә Аллаһыдан бирелгән әмер, борын-борыннан билгеле бер нәселгә тапшырылган бурыч дип ышана җирле халык. Бу нәсел кешесе астана йоласын үтәп яшәргә, бозыклыктан, явызлыктан, һәртөрле начар уй-гамәлләрдән азат булырга тиеш. Әгәр шушы кагыйдәдән чыкса, аның үзенә генә түгел, нәсел-нәсәбенә бәла килә. Андый очраклар да булган. Халык хәтерли, әнәсеннән-җебенә кадәр сөйләп тә бирә. Бүген Казанлы астанасы, ягъни астананың төзеклеге өчен җаваплы кеше – Әшрәфҗамал исемле карчык.

Моннан тыш, Төмән өлкәсендәге һәр астананың үз тотемы бар. Әйтик, бу якларда иң олы астана булган Кече Уват (халык телендә – Малай Уват) каберлегенең символы – Үгез. Казанлыда ул – Каз. Халык үзе моны Бохарадан килгән билге дип аңлата. Бу күпмедер дәрәҗәдә мәҗүсилекне, борынгылыкны чагылдырган күренеш буларак кызыклы.

Төшендә астана тотемын күргән кеше тиз арада астана хуҗасына сәдака китерергә тиеш икән. Сәдака итеп тәңкәле акча алына, ул кызыл чүпрәккә төрелә. Шуннан соң гына төш күргән адәм сәдакасын илтеп тапшыра. Тәртибе шулай. Халыкта моны «шык сәдакасы бирү» яки «шыкка төю» дип йөртәләр. Шык сүзенең «изгеләр каберен караучы» дигән мәгънәсе бар. (Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Т.2. – Казан, 2015. – Б. 497). Нәзере булса, яисә бәла-каза килсә дә кеше шыкка төяргә, ягъни астананы караучыга хәер-сәдака төенләргә мөмкин. Шык сәдакасын Төмән өлкәсендәге һәр астанага берәрне таратып чыгу гадәте дә бар. Астанага шык сәдакасы бирергә уеңа килгән булса, аны һичшиксез астана хуҗасына илтеп тапшыру мөһим.

Тарихтан билгеле булганча, XIV гасырда Көнбатыш Себердә Урта Азиядән килгән мөселманнар – шәехләр мәҗүсиләргә каршы корал тотып көрәшкәннәр. Халык үзе дә: «Бу җирләрдә бик каты сугышлар булган», – дип сөйли. Шәехләрнең коралллы гаскәрләре, исламны инде кабул итәргә өлгергән җирле халык белән берлектә, Себер олысында бохара ханнарының, татар феодалларының һәм, әлбәттә, ислам диненең йогынтысын ныгыту өчен, көрәш алып барганнар. Шушы вакыйгалар нәтиҗәсе буларак, Себердә яшәүче җирле татарлар арасында ислам таралган.

## РИВАЯТЬЛӘР НИ СӨЙЛИ?

Астаналарга багышланган риваятьләрне һәр йортта беләләр монда. Күрәсең, изге гореф-гадәтләрне шулай күркәм рәвештә буыннан-буынга тапшыра киләләр. Менә, мәсәлән, Сөләйман авылыннан Мөнәвәрә Җамалетдин кызы Мөгамәтуллина (1933 елгы) Паеш астанасы турында мондый риваять сөйләде:

«Бохарадан килгән муллалар мондагы халыкны дингә өйрәткәннәр. Аларны саклап килгән солдатлар булган. Әллә ничә йөзләп шундый кеше үтерелеп, күмелгән җирне бездә «астана» диләр. Паеш астанасы – Иртеш аша яхшылар яткан җир. Инде алар кешенең төшенә кереп, үзләрен белдерткәннәр. Бер хатын Паеш астанасын карап торган. Иртән ире торганчы, яланаяк Иртешне атлап чыгып, яхшыларны зыярәт итеп кайта икән. Ире белгәнче, шулай караган астананы. Бервакыт ире күзәтә бара моны. Иртеш аша чыгып та хатынының батмавына исе

**Тарихтан билгеле булганча, XIV гасырда Көнбатыш Себердә Урта Азиядән килгән мөселманнар – шәехләр мәҗүсиләргә каршы корал тотып көрәшкәннәр.**

китә. Ире күргәч, хатын балтырыннан бата суга. Шул хәлдән соң, ирем көнләшә, дип, астананы нәселендәге башка кешегә тапшыра».

Тәрбияви әһәмияте ягыннан гаҗәеп тәэсирле булып тоелган «Кәтербәт сазлыгы риваяте» дә шул ук бохара «яхшылары»на барып тоташа. Аның «Нугайдагы алтын риваяте» дигән исеме дә бар. Түмән өлкәсенең төрле авылында бу вакыйганы төрлечә сөйлиләр, әмма сюжет, мәгълүмат – бер үк, асылы – үзгәрешсез. Бу риваятьнең Казанлы авылыннан Хәлим Харис улы Сәгыйдуллиннан (1949 елгы) һәм Тугыз авылыннан Гөлҗамал Садыйк кызы Шамратовадан (1937 елгы) ишеткән вариантларының җыелма тексты түбәндәгедән гыйбарәт:

«Малай *(Малый, ягъни Кече. –* **Л.М.***)* Уват белән Большой Уват арасында кырык биш чакрым озынлыктагы, унбиш чакрым киңлектәге күл бар. Аны Олы күл диләр. Тирәвене *(тирә-юне. –* **Л.М.***)* «Нугай кыры» дип атала. Күл кырында авыл булган. Элекке заманда. Ул вакыт без дә булмаган. Бу күлдә балык тотканнар. Кәтербәт сазлыгы шул күл янында. Анда яхшылар алып килгән алтын күмелгән.

Бервакыт Нугай авылына яшь килен төшкән. Ул килентәшкә күлдән алтын чыгып утырган. Юан *(зур. –* **Л.М.***)* чүген *(чуен. –* **Л.М.***)* булган, имеш. Өч көн рәткә киләте бу килентәш күл буена, өч көн рәткә алтын чыгаты. Анда энҗе-мәрҗәннәр, ат сбруйлары, унике штук алтын ияр булган. Килен моны беркемгә дә әйтмәгән, байлык үземә генә булаты, дигән. Ул килентәш алтынны шулай өч көн уйната икән карап торып.

Инде дүртенче көн баруына чүген казан да юк, алтыннар да юк. Аннан килен авылга кайтып сөйләгән: «Мин сезгә әйтмәгән идем, ул шундый-шундый урында шулай-шулай батып китте», – дигән.

Шуннан бер карт мулланы ияртеп, күл буена барганнар. Мулла китап тотып барган, аннан китап ачкан да әйткән: «Авылдан бер начар кеше чыкты, ул килеп җиткәнче алсак, җитешәбез, өлгермәсәк, алтын төпкә китәр». Алтынны чыгара башлаганнар икән дә, чыгарып бетергәндә генә мулла әйткән теге кеше болар янына килеп җиткән. «Миңа өлеш калдырыгыз», – дип кычкырган. Шуннан алтын төпкә төшкән киткән, тотып кала алмаганнар.

Карт мулла полтар караган *(фал ачкан, баккан. –* **Л.М.***)* һәм әйткән: «Котык токымнан (Коелар нәселе) ак чәчле, күк күзле кыз бала туар, күз иясе *(уртасы. –* **Л.М.***)* кызыл булыр. Унсигез яшенә җиткәч, алтын аңа чыгар, ул ала алыр байлыкны», – дигән. «Алтын аңа чыгып утырыр, курыкмаска кирәк. Алтын янына килеп, юан *(зур. –* **Л.М.***)* пычак алып, корбан чалсын», – дип өйрәткән. «Корбан чалганда: «Байлыгым бөтен илгә, миргә булсын», – дип чәнечсен. Ул вакыт алтын батмай», – дигән.

Котык токымда, мулла әйткәнчә, чыннан да ак чырайлы, ак чәчле, күк күзле, күз уртасы кызыл бала туа. Әмма кызга унсигез тулганда аны алтын яткан җиргә – Кәтербәткә алып чыгучы булмый, чөнки әтисе сугыштан кайтмый калган, әшнең рәтен белүче башка кеше юк. Шулай итеп, алтын төптә кала.

Мулла тагын әйткән була: «Әгәр дә кыз ала алмаса, Котык токымның җиде буынынача китәр: унсигез елдан унсигез елга шул ук нәселдә шундый ук бала туар. Алтын табылганчы. Җиде буынга җиткәнче алтын табылыр. Котык токымга әйтелгән алтын бу».

Әмма шунысы да бар диләр: «Котык нәселе иманлы, шәфкатьле, изге нәсел булып дәвам итәргә тиеш. Әлеге нәсел кешесенең күңеле гел чиста, керсез булуы кирәк. Комсызларга, затсызларга Нугай алтыны чыкмайты, булмайты». Котык нәселе бүген дә яши, ди, халык аларның кемнәр икәнен яхшы белә, кызыл күзле, ак тәнле ир бала хәзер уналты яшьтә диделәр.

## СЕБЕР МӘРГӘННӘРЕ

Мөгамәтали мәргән белән Кузы Нияска, аючы Хәйбуллага, Атамыш аучыга багышлап матур-матур кыйссалар сөйләделәр Себер җирендә гомер итүче милләттәшләребез. Аларда биредә яшәп киткән кешеләр турында сүз бара, боларның исемнәре халык теленә юкка гына кермәгән. Гаҗәеп батыр, пәһлеван, төз атуда тиңсез оста булганнары өчен онытмый аларны халык. Мөгамәтали мәргән, мәсәлән, яхшылар нәселеннән, ягъни Бохарадан килгән шәехләр токымыннан булган. Халыкта аның оста мәргәнлеге, җитезлеге, батырлыгына багышланган, яисә башка мәргәннәр белән көч сынашулары хакында күп кыйссалар телдән-телгә йөри. Мәсәлән, Мөгамәтали белән күрше авыл мәргәне Кузы Ниясның төз атуда көч сынашуы турындагы кыйсса хәтердә уелып калды. «Кузы Нияс оста чаңгычы булган. Песнең якларда аучының эте карап өргән агачтан иң яхшы чаңгы ясаганнар. Чаңгы ясарга агач сайлаганда аучының эте кайсы агачка карап өрә, шул агачны аударганнар. Наратның озынына, яшенә, формасына карап эстәгәннәр, эт тә аңа карап өрсә, яхшы саналган. Иң елгыр чаңгы Тугыз авылыныкы яхшылар нәселеннән Кузы Ниязта икән. Кузы Нияс чаңгысының эзе калмый булаты. Оца торган чаңгылар булаты. Уват авылыннан Мөгамәтали мәргән белән урманда очрашканнар да көч сынашып карамакчы булганнар болар. Сөйләшкәннәр багып атуга *(багып ату – яшертен барып ату. –* **Л.М.***)*. Чаңгылар белән булганнар. Аңны *(поши. –* **Л.М.***)* күргәч, Мөгамәтали мәргән мылтык төзәгән аткалы. Шул вакыт Кузы Нияс ботакны сындырган аңны кацыру өчен, Мөгамәтали мәргән ата алмый калган, аң олагып цыгып кацкан. Шуннан Кузы Нияс аңның артыннан чаңгысында куып җиткән дә атып еккан аңны, бугазлаган, аннан кайтып киткән. Кузы Нияс кацып барган аңны чаңгысында куып йитеп атып алган булаты. Өстен чыккан Мөгамәталидән. Мөгамәтали барып караган, моның чаңгы юлы булмаган, эзе күренмәгән. Халыкка кайтып сөйләгән хәлне. Халык шикләнгән Кузы Ниястан, моның суда юынуын көткәннәр. Бер кеше

**«Бохарадан килгән муллалар мондагы халыкны дингә өйрәткәннәр. Аларны саклап килгән солдатлар булган. Әллә ничә йөзләп шундый кеше үтерелеп, күмелгән җирне бездә «астана» диләр.**

күргән: Кузы Ниясның култык астында канатлары бар икән, юынганда болар күренгән. Кузы Нияс карап торучы кешегә арты белән торса да, аны күргән, кыцкырган: «Беркемгә сөйләмә, сөйләсәң, петәсең!» – дигән. Аның канатын күргән кеше Кузы Нияс картаеп үлгәч, аны сөйләгән. Шуныңчы сөйләмәгән. Кузы Ниясның оца торган чаңгылары әнә шул каурый-канатларыннан булаты». (Информант – Казанлы авылыннан Хәлим Харис улы Сәгыйдуллин (1949 елгы)).

Ауда йөргәндә хәтәр хәлгә очрап, зирәклеге, батырлыгы, көче аркасында котылып калган Атамыш аучы кыйссасын, берүзе бик дәү аюга каршы чыгып, җиңү яулаган аючы Хәйбулла бабай турындагысын һәм башкаларны сөйләгән вакытта информант: «Бу булган хәл», – дип өстәп куя. Шунысы кыйммәт: әлеге кыйссаларда халкыбызның героик дастаннарыннан килә торган рух бар. Ул – батырга дан җырлау, аның гадәттән тыш көчле булуын ассызыклау, каһарманлык. Мөгамәтали мәргән, Кузы Нияс, аючы Хәйбуллага багышланган шактый күләмле бу кыйссалар атаклы «Алпамыш», «Йиртөшлек», «Кадыш Мәргән» һәм башка дастаннар традициясен дәвам итәләр. Әлбәттә, кыйссаларның без язып алганнары әллә ни ерак гасырларга карамый, алай да халык иҗатының бүгенге көнгә, заманга туры килә торган иҗат җимешләре алар. Себердә яшәүче татарларның тормышы кош, җәнлек аулау белән тыгыз бәйләнештә. Менә шушы бәйләнеш аларда батыр аучы-мәргәннәр турында мавыктыргыч әсәрләр барлыкка китергән һәм, аеруча мөһиме, күргәнебезчә, тел-авыз иҗатында мондый кыйссалар әле дә очрый.

## ЙЫШ ҺӘМ ЙЫШ ИЯ, ЙЫШКА ЮЛЫККАН АУЧЫЛАР ҺӘМ ҖЕН КАРЧЫГЫ ИЗУРЧЫК

Урман яки Күл иясе адаштырган, яисә, белештермичә, урман иясенә – Йышка өйләнеп харап булган аучылар турындагы хикәятләр – Себердә очрый торган эпик фольклорның бер тәркеме. Мифик чыгышлы хикәятләр дип билгеләргә мөмкин аларны.

Йыш – Шүрәлегә охшаш образ, әмма аның гадәте кешеләрне кытыклап үтерү түгел, ә калын урман эченә алып кереп адаштыру. Йышка яки Йыш иягә (монысы ир затыннан булган урман иясе) юлыккан кеше, кая барганын абайламыйча, йөгерә-атлый урман эченә кереп китә, тәмам хәлдән тайганчы адашып йөри. Шуңа күрә Ияләрнең – урманныкымы ул, күлнекеме, йорт-кура, мунчаныкымы – ачуын кабартырга, аларга ошамаслык начар гамәлләр кылырга ярамый, чаманы югалтырга, тыелган эшне кылырга ярамый дип белә халык. Моның шулай булуына дәлилләр китереп сөйлиләр. «Бер сунарчы күлдә йөргән. «Йиргә ятма, йоклама сунарда», – дигәнне белсә дә, яткан. Йоклаган. Төшенә өч кыз керә моның. Сине яраттык, диләр сунарчыга, беребезне ал, диләр. Шуннан уянып китә бу, кызны алып кайта, белми Йыш икәнен, шуның белән яшәйте. Үзе сунарга йөри. Бичәсе бу кайтуга тәмледән тәмле ит ризыклары әзерләп куя икән һәм әйтә: «Кайтканда ишекне гел шакып кер, юкса ачуланышырбыз», – ди. Ир шиккә төшә, каян алып пешерә дип. Бервакыт ишекне шакымый кайтып керә дә күрә: хатын аннан бет ала, моннан борча тота да сумсалар, пилмәннәр ясый ди шулардан. «Ишектән кердем, тәрәзәдән чыгам!» – дигән дә чыгып очкан ди ире искәрмәстән кайтып кергәч. Дүрт баласы калган. Токымнары әле дә бар ди. Күзләре канлы, кызыл. Ул сунарчы яшәгән йорт урынына бүтән берәү дә йорт салмаган». (Информант – Сөләйман авылыннан Мөнәвәрә Җамалетдин кызы Мөгамәтуллина (1933 елгы)).

Җен карчыгы Изурчык белән төне буе җеп эрләүдә ярышкан Кече әби, пәри хатынына кендек әбисе булган корткаякка багышланган мифик риваятьләрне дә Себер татарлары ихластан бирелеп, бик мавыгып бәян иттеләр.

## КЕММЕ, ӘЛЛӘ НӘРСӘМЕ УЛ КУПКАН?

Аерым бер төркемдә – үлгәннән соң җиде кабер аша чыккан кан эчүче зат – Купканнарга, алар белән бәйле маҗараларга багышланган хикәятләр. Аларны тыңлаганда тын алырга да куркыта, кичке караңгы төшкәч урамга чыгарга шикләндерә.

«Купкан – бу дөньядан туймый китеп кузгалган кеше пулаты, – дип аңлаталар Себер татарлары. – Кире кайтып, кешеләрне куркытып йөрите. Каты кузгалып йөри башласа, кешеләргә зыяны арта. Бик азып киткән Купкан кешеләргә тия, аларның канын эчеп йөри башларга мөмкин». Мондый хәл булмасын дип, алдан ук чаралар күрелә икән.

Купканны басу өчен Коръәннән уналты сүрә укый-укый иң элек өч кат зиратны әйләнеп чыгарга кирәк. Шуннан шул ук сүрәләрне киресенә укыйсы. Бер хәрефен дә ялгышырга ярамый. Ялгыштың – беттең дигән сүз, я үләсең, я гомерлеккә гарип каласың. Шуныңчы укыйсы – кем кузгалган, шул алдыңа килеп басканчы. Купкан каршыңа килеп баскач, кирәкле аятьне укып, аңа урынына кереп ятарга кушасың. Шулай иткәч, Купкан каберенә кереп ята. Бу эшне укымышлы мулла гына башкара ала икән. (Информант – Тугыз авылыннан Сөлҗамал Ситдыйк кызы Пахметова (1926 елгы)).

Таңнан торып, җиде өйнең чүбен себереп алып, аять укып өшкертеп, зиратка алып барып, Купкан чыга торган җиденче кабер тишегенә салсаң да Купкан басыла, имеш. (Информант – Тугыз авылыннан Гөлҗамал Садыйк кызы Шамратова (1937 елгы)).

«Кем кузгалганын белү өчен зиратта каберләрнең комын карап цыккалы гәрәк. Кузгалган кешенең кабере өстендә комы иләктән иләнгән кебек пулаты. Әүвәл син шуны сизеп, кем кузгалуын белсәң, Купкан төнлә төшеңә керәте, беркемгә дә сөйләмәскә кушып, куркыта», – дип сөйлиләр информантлар. Бу дөнья белән теге дөнья арасындагы бәйләнешкә караган гаять серле тема булгангамы, мавыктыргыч итеп сөйләнгәнгәме – бирелеп китеп тыңлап утырам. Бу өлкә гомер-гомергә адәм баласында зур

кызыксыну уяткан, адәм акылы аңлый алмастай күренешләргә халык үз бәясен биргән, исламга, Аллаһы ярдәменә таянып, боларга карата үз җавабын да тапкан, күңелен шулай юаткан.

Әле шундый хәлләр дә булган, имеш, Купканны Коръәннән аятьләр укып басарга муллаларның гына көче җитмәгәч, бик каты кузгалып йөри башлаган берәүнең каберен ачып, башын чапканнар. Ул исә башын култык астына кыстырып йөри башлаган. Ахырда аның күкрәгенә казык какканнар. Аннан соң да туктамаса, андыйны яндыралар икән. Купкан турында сөйләүче ялгыш та аның исемен телгә алмый. Юкса каршыңа чыгуы бар, дип ышаналар. (Информант – Казанлы авылыннан Мәүлига Нәгыйдулла кызы Рәхмәтуллина (1902 елгы)).

«Кая соң ул Купканнарыгыз, нигә миңа бер дә очрамады?» – дигән соравыма да аңлаешлы бик матур җавап алдым: «Фәрештәләрең яхшы саклый торган, димәк. Кешене саклаучы фәрештәләр аның күзенә җен-пәриләрне дә, купканнарны да күрсәтмиләр, кешене алардан саклыйлар. Аннан болай артык курыккан вакытта, я бик ашыгып йөрүче кешегә дә андый нәрсәләр күренми. Андыйлар, кабаланып, җеннәрне таптап ук уза. Шуңа күрә бүгенге көндә кул-аягы сынык җеннәр күп һәм алар кешеләргә ачулы» (Информант – Казанлы авылыннан Флёра Рәхимҗан кызы Ватутова (1963 елгы)).

Миф, уйдырмаларга никадәр күңел аклыгы, садәлек сыйган! Юкка гына халык иҗаты аның күңел көзгесенә тиңләнми шул.

## УЙНАП-КӨЛЕП ЯШӘ, ХАЛКЫМ!

Әби-апалардан яшь чагында нинди уеннар уйнаулары турында сорашам. Себердәге милләттәшләребезнең «Саргынаем», «Аралап алышмак», «Өзелешмәк», «Тилгән», «Каешлы» дип аталган җырлы-биюле уеннары Казан татарларының «Назалы», «Түгәрәк», «Тамчылы» һәм башка уеннарын хәтерләтә, әмма җыр текстлары, такмаклары, көйләре үзенчәлекле:

«Яшь чакта «Саргынаем» уйный торган идек. Етәкләшеп басасың да ер ерлайсың бер-береңә такмак-такмак:

*Сөләйманнан уң якка*
*Казанлы авыл – бай авыл.*
*Сөләйманның складына*
*Хәтирә туташ каравыл.*
*Убай юлы, Убай юлы*
*Убай юлы канаулы,*
*Мин синең сөйгәнең күрдем –*
*Скрипка танаулы.*
*Сөләйманның буйдаклары*
*Аюның табанынтай,*
*Казанлының буйдаклары*
*Алманың сабагынтай.*

Етәкләшеп түгәрәктә әйләнәсең. Уртада бер пар тора. Такмак бетсә, бу икәү түгәрәккә чыгып өерләнә, янә ике кешене этеп уртага чыгаралар да тагын ерлайлар». (Информант – Малай Уват авылыннан Маһинур Хәлил кызы Шәяхмәтова (1948 елгы)).

Авыл көенә җырлана торган әллә никадәр кыска җыр язып алдым биредә. Казанлы авылында Рабига Әмин кызы Мөгамәтуллинадан (1931 елгы) гына да шундый 80 куплет җыр теркәлде. Биредә Карагай авылында Ваби исемле кеше яшәгән, ул сукыр булган, авылдан-авылга йөреп тамак туйдырган. Аны оста импровизатор – такмак чыгаручы буларак хәтерлиләр, такмакларын да онытмаганнар. Ваби 1950 елларда дөнья куйган.

Түбән өлкәсе Вагай районында яшәп ятучы милләттәшләребез белән аралашу татар фольклористикасын яңа эпик образларга, фольклорга бәйле сюжетларга баетты, туган телебезнең никадәр бай булуына янә бер кат инандырды. Түмән өлкәсе татарларында халык иҗаты материаллары бар һәм күп. Тарих чоңгылының матди булмаган бик күп рухи байлыкны йота барганлыгы аңлашыла. Алай да халык авыз иҗаты, бүгенге көнгә яраклашып, чагыштырмача гөрләтеп яши әле биредә. Себердә яшәүче татарларның бай тарихы, борынгылыкны саклап калган җирле сөйләшләре, гореф-гадәт, йолалары белән бергә телдән-телгә тапшырылып килгән риваятьләре, мифологик хикәятләре, героик дастаннар төркеменә кертерлек кыйссалары – заман фольклорының тиңсез хәзинәләре.

# «Гаиләм – илһам чишмәсе»

(Сценарий)



*Рәйханә СТЕПАНОВА,*
*Кукмара, 7нче «Кыңгырау» балалар бакчасы тәрбиячесе*

*(Матур итеп бизәлгән татар өе. Сәхнәдә эскәмия тора. Кызлар, әниләр эскәмиягә утырып сөлге чигәләр. «Сөлге чигәм» җырын (Фасил Әхмәтов көе, Хәлим Җәләлов сүзләре) башкаралар. Читтәге урындыкта бер малай кәрзин үрә. Кыз йөгереп керә.)*

**Кыз:** Исәнме, әнием! Син ни белән шөгыльләнәсең биредә?

**Әни:** Кызым, сөлге чигәм. Күрче, ничек килеп чыкты?!

**Кыз:** Әх! Нинди матурлар, нәкъ әбием өендәге кебек!

**Икенче кыз:** Безне бу эшкә әбиебез өйрәтте. Элгәре мондый сөлгеләр һәр өйнең бизәге булган, һәм иң кыйммәтле бүләк булып саналган.

**Әни:** Танылган кул эшләре остасы иде әбиең. Үзе тукыган сөлгеләр белән Кукмарада дан тота иде. Әйдә әле, утыр, кызым! Кулыңа киерге ал! Хәзер әтиләрең дә кайтып җитәр.

*(Кыз әнисе янына эскәмиягә утыра, кулына киерге ала. Гармун моңы ишетелә. Сәхнәдә малайлар, әтисе пәйдә була. «Күбәләгем» җырын (татар халык җыры) башкаралар.)*

**Әти:** Исәнмесез, чибәр кызлар! Борай ярмасыннан пешерелгән вак бәлеш белән сыйланырга килдек әле.

**Кыз:** Ә безгә ни бирәсез?

**Малай:** Бүләккә – бабаең өйрәткәнчә басылган киез итекләр һәм башмаклар менә.

**Кыз:** Безнең гаилә гомер-гомергә үзенең кул эшләре белән дан тоткан бәрәкәтле Кукмара җирендә яши.

*(Дефиле. Кызлар Кукмараның итекләрен күрсәтә.)*

**Әни:** Басуда эшләп кайтканнан соң, әбиләрнең өйдә җыелып, кул эшләре белән шөгыльләнгәннәрен әле дә хәтерлим кызым. Без дә әби-бабаларыбыз мирас итеп калдырган традицияләрне онытмаска тырышабыз, һәм ул хакта сезгә гел сөйләп торам, кызым, шулай бит...

**Кыз:** Әйе, әнием. Борай бәлеше – гаиләбезнең яраткан милли ризыгы.

*Бик тәмле дә, файдалы да,*
*Борай бәлеше бит ул!*
*Президентлар өстәлендә,*
*Күркәм урында нәкъ шул.*



*Иренмичә әзерләгез,*
*Ашыгыз тәмле булсын!*
*Бәлеш исе өйне бизи,*
*Өебез ямьле булсын.*

**Әни:** Әбиеңнең әнисе – минем дәү әнием үзенең оста куллары белән доганы матурлап язып, бәла-казалардан саклагыч шәмаил ясаган. «Моны саклаган кешенең өендә һәрчак бәхет һәм муллык булыр» дигән ул. Әлеге шәмаилне әбиеңә биргән, аның гаиләсе һәрчак бәхетле булды, ә әбиең миңа тапшырып калдырды.

**Кыз:** Әйе, әнием, бик кадерле бүләк. Мин дә аны саклап тотармын, безнең гаиләдә дә һәрчак иминлек һәм җылылык булыр.

**Кыз:** Мин буш вакытымны әнием белән бергә үткәрергә яратам. Ул миңа тормыш серләре турында сөйли, аның белән бергә үзебезнең дус, тату гаиләбез өчен төрле тәмле, милли ризыклар әзерлибез. Ә этием минем «алтын куллы». Ул агач эшкәртү серләрен бик яхшы белә. Төп хезмәтеннән тыш, һәрчак йорт мәшәкатьләре яки бакчадагы эшләр белән мәшгуль. Ул безнең һәрберебез өчен үрнәк.

*(Бала елаган тавыш ишетелә. Кызлары бишек алып чыга. Бишектәге кечкенә кыз балага карап тора.)*

**Әни:** Мин бишектә үстем, абыйларың да, син дә. Элек-электән безнең өйдә бишек җырлары яңгырады. Абыең тугач та, аның начар ишетүенә карамастан, мин аның өчен бишек җырларын зур ярату хисе белән, үтемле итеп башкарырга тырыштым. Үсә төшкәч, абыең безнең өметебезгә һәм терәгебезгә әйләнде, ул хуҗалыгыбызда, йортыбызда зур ярдәмчебез. Бүгенге көндә бик мавыгып, тал ботакларыннан искиткеч матур кәрҗиннәр үрә.

*(Кызлар малай үргән кәрзиннәрне алып чыгып күрсәтәләр.)*

**Кыз:** Тырышлык, эш сөючәнлек – гаиләбез ныклыгының нигезе.

**Икенче кыз:** Сезнеке кебек гаиләләр районыбызда бик күп. Аларның куллары белән гаилә иминлеге, димәк, республикабыз иминлеге дә булдырыла.

*(«Минем гаиләм» җыры башкарыла.)*

**Кыз:** Мин үз гаиләм, аның уңышлары, нәсел-тамырларыбыз, шәҗәрәм белән горурланам. Гаиләм мине яңа уңышларга канатландыра. Ул миңа шатлык һәм бәхетле тормышта яшәү тойгысы бирә.

**Әни:** Безнең күркәм гаилә бик бәхетле һәм ныклы. Һәрчак шулай булсын иде дип телим.

# ФАЛЛАР

*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*



**Фаллар – һичшиксез, мифологиянең иң кызыклы жанры. Магик йола белән ырым традицияләре очрашкан урында туган ул. Башкача да әйтергә мөмкин: фаллар – безгә мәгълүм юрамышларның йола рәвешен алган югары рәвеше. Күрәзәлек, багучылык белән бәйле йола системасы.**

Әйе, кеше гомере буе хәерле, бәрәкәтле гомергә, мәхәббәтле, тигез гаилә тормышына, бер сүз белән әйткәндә, чын, олы бәхеткә омтылган. Шушы омтылыш аның хыялын уйнаткан, уйларына канат биргән. Күрәзәчелек, багучылык йолалары аңа ярдәмгә килгән.

Фал йолаларын, фал ачуларны, нигездә, йә кояш баеганда, йә төн уртасында, йә таң алдыннан башкаралар. Чөнки кич, төн, таң – табигатьнең иң сихри, хәтта шаукымлы-магик вакыты, икенче төрле әйткәндә, рухларның, ияләрнең, җеннәрнең, изгеләрнең, күрәзәче-әүлияләрнең актив яшәү мәле. Һәм алар, күп очракта, адәми затларның омтылышларына теләктәшлек итәләр, аларга ярдәмгә киләләр. Әгәр язмыш язылган булса, алар әнә шул язуларның дөрес башкарылуын тәэмин итеп торалар... Һәрхәлдә, фалчылар, багучылар шулай уйлаганнар...

Халкыбызның мифологик мирасында ике йөзгә якын фал йоласы теркәлеп калган. Алар арасында балалар уенын хәтерләткән примитив фаллардан башлап, язма әдәбиятның югары кимәлендә булган, тирән психологик анализны, гасырдан-гасырга күчеп, баеп килгән, бер үк вакытта мәҗүси тәгълиматны да, дини өйрәтмәләрне дә күз уңында тоткан, күпгасырлык халык фәлсәфәсен нигез итеп алган легендар «фалнамәләр» дә бар. Катлаулы фалларны бары тик профессионал багучылар, күрәзәчеләр, фал ачучылар гына башкара алган.

Фалларны өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

## ГАДИ ФАЛЛАР



Юрауның, багуның иң примитив формалары гади халык арасында, бигрәк тә авыл җирлегендә яшәүче үсмерләр, яшьләр арасында киң таралган була. Алар, уеннар катнаштырып, күбрәк кызык өчен башкарылганнар. Бу фал йолаларында һәр кеше катнаша алган һәм аны үзе дә оештыра алган. Ничек кенә гади һәм примитив булмасын, фаллар өчен мөһим булган

> Юрауның, багуның иң примитив формалары гади халык арасында, бигрәк тә авыл җирлегендә яшәүче үсмерләр, яшьләр арасында киң таралган була. Алар, уеннар катнаштырып, күбрәк кызык өчен башкарылганнар.
> Бу фал йолаларында һәр кеше катнаша алган һәм аны үзе дә оештыра алган.

күрәзәлек, багучылык күнекмәләре монда да ачык ярылып ята: «Нәрсә булыр?», «Кем булыр?», «Кайчан булыр?», «Нинди булыр?». Шундый халыкчан йолаларның берничәсен карап китик.

***Чабата фалы.*** Яшүсмерләр, бигрәк тә кыз-кыркын арасында киң таралган бу фал, чынлап та, беренче карашка балалар уены кебек кенә. Ул бик гади: койма-капканың эчке ягына (ишегалдына) яшьләр җыела. Арадан берәү – фал ачыласы кеше – кулына чабатасын (яисә башка аяк киемен) алып, аны урам ягына ыргыта. Аннары яшь-җилкенчәк дәррәү рәвештә урамга чыга. Карыйлар: чабатаның (яисә башка аяк киеменең) башы кайсы якка караган? Бөтен сер дә шунда – чабата башы караган якта бактыручының сөйгән яры, кияве (кәләше) яши, имеш. Кайбер төбәкләрдә: «Кияү (кәләш) шул яктан булачак (киләчәк)», – дип тә әйтәләр.

Әлеге фал кайбер татар авылларында койма аша киез итек, читек, тула оек, оекбаш, чүәк ташлау ысулы белән дә башкарыла.

Бу фал йоласына охшашлы башка йолалар да бар. Шундыйлардан «Таяк фалы», «Аркан фалы», «Яфрак фалы», «Җеп фалы», тагын уннарча фал йолаларында фал ачучының (бактыручының) язмышы аның кулыннан ташланган яисә очыртып җибәрелгән предметларның кайсы якка каравы, очып китүе, юнәлүе аша ачыклана.

***Сарык фалы.*** Бу фал йоласын төн уртасында башкаралар. Бу очракта да, төн уртасы җитүгә, бер төркем егетләр-кызлар абзар алдына җыелалар. Араларыннан берсе дөм караңгы абзар эченә кереп китә дә кулына эләккән беренче сарыкны тотып алып чыга.

Бактыручы кыз карый: яшь сарык эләксә – яшь кешегә, карт сарык эләксә – карт кешегә кияүгә чыгачак. Сарыкның нинди төстә булуы да мөһим: ак сарык тотылча – әйбәт, гадел, ак күңелле, ак йөзле кешегә, кара сарык тотылса – караңгы чырайлы, кара күңелле, мәкерле кешегә кияүгә барырга туры киләчәк. Йоны коелган сарык эләксә, фәкыйрьгә бара, имеш.

Барда татарлары бу фалны тавыклар (әтәчләр) белән башкаралар (ак тавык (әтәч) – бәхеткә; кара тавык (әтәч)) – бәхетсезлеккә һәм башкалар.

Ишектән, капкадан беренче кергән кеше, урамда беренче очраган кеше белән бәйле фал-ышанулар, күрәзәлек итүләр дә гади фалларга карый.

***Тула фалы.*** Мари иленең Бәрәңге районына кергән татар авылларында язып алынган. Аның тәртибе шуннан гыйбарәт: туланы баскан вакытта ишектән кем керә, бигрәк тә бер яшь кыз керсә, аңа туланың бер башын кисеп бирәләр дә ишектән чыгарып җибәрәләр. Урамга чыккач, кем беренче очрый – бу кыз шуңа кияүгә барачак, имеш. Кайчакта бу фал йоласын тагын да гадиләштерәләр: карт бабай очраса – карт кешегә бара, егет очраса – егет кешегә кияүгә чыга.

Тау ягы керәшеннәрендә башкачарак сынала. Тула басучы башлап ак тула басса – сынап торган кызның кияве ак егет була, кара тула басса – кара егеткә кияүгә бара. Башкача да сыныйлар: тула басучы янына килеп кергәндә тулачы нинди төстәге туланы басып торган чак була – кияү шундый була: ак тула – әйбәт кеше, бәхеткә; кара тула – начар кеше, бәхетсезлеккә.

Кайчакта тула урынына киез итек (пыйма) белән дә сыныйлар.

***Сөлге фалында*** да бар бу юрамыш. Бу очракта үзәккә сөлге тукучы кызлар чыга. Сөлге тукып бетергән көнне алар бәхетләрен сынап, фал ачалар. Капкадан киез итек ыргыталар.

Аның башы кайсы якка яткан булса, бактыручы кыз шул якка кияүгә китә, имеш.

Икенче бер хәбәрдә сөлге тукучы кызлар, чүпләү калакларын кабып, дәррәү урамга йөгереп чыгалар. Кайсы яктан эт өрә, бактыручы кыз шул якка кияүгә китә. Яисә: беренче күргән кеше карт булса – карт кешегә, яшь булса – яшь кешегә кияүгә китә.

Бу фалны сөлге суккан кыз белән турыдан-туры да бәйләп сыныйлар. Сөлгече кыз, яңа гына суккан тастымал башын җилкәсенә салып яисә муенына урап урамга чыга. Нинди кеше очрый: карт кешеме, яшь кешеме – шундый кешегә кияүгә чыга.

***Киндер фалында*** исә киндер суккан кыз, бәхетен юрап, бер киндер кисәген уң беләгенә бәйләп урамга чыга. Карый: беренче кем очрый – картмы, яшьме? Шул беренче күргән кеше буенча язмышын юрый.

***Йолдыз фалы*** да бу теманы дәвам итә. Ул да кичләрен яисә төнлә сынала. Яшьләр, авыл уртасына җыелып, күккә багып торалар. Кайсы яктан йолдыз атылса, шул якта (урамда, очта) яшәүче егетләр, кызлар бәхетле булалар.

Икенче очракта, башта кемнең дә булса исемнәрен атыйлар, аннары аның сөйгән яры кайсы якта яшәгәнен яисә кайсы яктан (авылдан) киләчәген багалар – иң беренче атылган йолдыз кайсы якта була, сөйгәне дә шул яктан килә яисә шул якта яши, имеш...

***Төш фалы.*** Бу фал да, нигездә, йолдызлар белән бәйле. Һәм ул бик гади: сигез көн йолдыз санап, бер сүз дәшми-нитми, беркемгә серенне әйтмичә, тугызынчы көнне кереп ятып, төш күрсәң, кемгә барачагың күренә.

Вариант: тулы ай калыккач, ягъни, айның унбишенче көнендә, төн аяз булса, күктәге йолдызларны санарга да йокларга ятарга кирәк. Бу мәлдә кеше белән аралашу, сөйләшү катгый тыела. Бөтен шартын да сакласаң, төшеңдә кемгә барачагыңны беләсең, имеш...

Тагын бер вариант: сөйгән кешеңнең туган көнендә, төнлә тышка чыгып, күктәге йолдызларны саныйсың да, кереп, йокларга ятасың. Бу төнне син төшеңдә сөйгәнеңне күрәчәксең...

Гади фаллар рәтендә карала торган ***Чыра фалы*** һәм аңа охшашлы башка «ут фаллары» да кызык. Бу очракта чырага (шырпыга) ут төртәләр дә югары күтәреп тоталар. Шырпы ялкыны кайсы якка ава – кияү шул яктан килә, имеш. Яисә шул яктан кадерле кунак килә. Шул якка юл төшә... дип тә юрыйлар.

Икенче бер очракта (***«Ут фалы»***) берәр мөһим эш башларга яки юлга чыгарга ниятләгән кеше башта бер чыраны идәнгә утыртып, бер ягына икмәк, бер ягына күмер куеп, шул чыраның төп ягыннан ут кабыза. Чыра янып бетеп, икмәк ягына ауса – эш, юл, ният уңышлы барып чыгачак, күмер ягына ауса – эшне башламау, юлга чыкмау хәерлерәк булачак.

## БОРЫНГЫ МӘҖҮСИ ФАЛЛАР



Икенче төр йолаларның күбесе ыругълык дәвереннән үк килә. Гадәттә, бу фал йолаларын халык арасында абруй казанган махсус фал ачып багучылар башкарган.

Мәҗүсилек чорында таш чәчеп фал ачу, сынау, юрау, багу, күрәзәлек итү аеруча киң таралган була. Шулардан ***«Бишташ фалы»*** (***«Камалак салу»*** дип тә йөртәләр) татарлар яшәгән һәр төбәктә дә очрый.

Биш бөртек ташны чөйгәннән соң, аларның җир өстенә ничек, кайда төшүләренә карап, үзен бактыручы яисә башкалар тарафыннан бактырылучы кешенең киләчәген, язмышын, теләк-ниятләрен, холык-фигылен белергә тырышканнар.

Менә шуларның берничәсе:

Ташлар тәртипсез ятсалар – таркау, тәртипсез тормыш көтелә.

Ташлар бөҗра ясап чәчелсә, алдагы тормышы бөтен, түгәрәк булыр, ниятләре гамәлгә ашар.

Ташлар бер рәткә тезелсәләр – алда (уңышлы) юл көтә.

Рәтнең бер очы киртләнеп китсә – юлның ахыры начар бетәргә мөмкин (яисә начар юл көтә).

Өч таш өчпочмак ясап җыелса, калган икесе эчке якта калса – бәхетле мәхәббәткә, тигез һәм сабыйлы гаилә тормышына.

Өч таш өчпочмак ясап төшсә, ә ике таш читкә китсә – авыр мәхәббәткә.

Өч таш өчпочмак ясап төшсә, бер таш шул өчпочмак эчендә калса, тагын берсе читкә тәгәрәсә – ямanlык (гайбәт сүз) көтелә, кемдер бәхетләрен җимерергә тели.

Ташлар, очлаеп, почмакланып төшсәләр – ачуланышуга, ызгышуга.

Дүрт почмакта дүрт таш булып, берсе аларның уртасына төшсә – бай, ныклы тормышка ия, әмма бик саран булу куркынычы да бар; берсе читкә төшсә – күңеле, яраткан кешесе, язмышы, мәнфәгате читтә. Бер ташның читкә тәгәрәвен, бик бай, мул тормыштан суырылып күп акча чыгачак, дип тә багалар.

Ташлар дугаланып, ярымтүгәрәк рәвешендә тезелеп ятсалар – дөньяң, тормышың кителә, бөтенлеген югалта, ярты-йортыга әверелә.

Өч ташка янәшә генә, икенче рәт булып, ике таш ятса – гашыйк буласың, кем беләндер дуслыгың ныгый. Яңа дуслар табасың, дип тә әйтәләр.

Югарыда әйтелгәннәр – фалның бер өлеше генә. Һәр багучы үзеннән ташлар тәртибе белән бәйле яңа фал-юраулар өсти, үз тәгълиматын «иҗат итә». Таш белән багучыларның бик осталары («Камалак салу» – үтә дә өлгерлек, осталык, исәп-хисапка сәләт сорый торган фал) үз йолаларында ташлардагы төртке-сызыкларны, аларның санын, тәртибен, арасын, рәвешен дә искә алалар.

Ни өчен биш таш соң? Мифологиядә билгеле факт: ташларның дүртесе дөньяның дүрт тарафын белдерә. Бишенчесе төрле очракта төрлечә: йә ул Җирнең үзәге, йә багучы (бактыручы) басып торган урын. Шул рәвешле Җир дөньясы биш тарафка бүленә. Багучы шул биш ташны күккә (Тәңре катына) чөеп җибәрә дә, аларның ничек килеп төшүләренә карап, бактыручының бу Җирдәге урынын, тормышын, язмышын күрәзәлек итә...

**Ногыт борчагы белән фал ачу.** 41 ногыт борчагы алалар. Аны киндер тукыма өстенә җәеп (өеп) куялар. Аннары шул өемне санап тормыйча гына өч өлешкә бүләләр (берсе – мәхәббәт, гаилә, икенче өем – байлык, муллык, өченчесе – язмыш, киләчәк). Соңыннан һәр өемнән дүртәр борчак саныйлар. Шулай бернична тапкыр санап алалар. Иң ахырдан калган борчаклар саны буенча фалның мәгънәсе чыгарыла. Ягъни фал ачыла торган кешенең гомер юлы, мәхәббәте, гаилә тормышы, хезмәттәге уңышлары, юлының уңу-уңмавы, иң мөһиме, бәхете сынала. Әйтик, ахырда төп-төгәл дүрт борчак калса – әйбәткә, бәхеткә, кавышуга һәм башкаларга. Өч борчак – ярыйсы гына тормыш кителә, уртача муллык-иминлек, таманча бәхет... Ә инде ике яисә бер генә борчак артып калса – начарга, уңышсызлыкка, бәхетсезлеккә, аерылуга, авыруга, һәлакәткә...

Соңгы чорларда, бигрәк тә хәзерге заманда ташларны, борчакларны кавырсын төймәләр, сәдәпләр алыштыра башлый. Ләкин йола үзе үзгәрми, традицияләр тулысынча саклана.

> «
> *Сөйгән кешеңнең туган көнендә, төнлә тышка чыгып, күктәге йолдызларны санайсың да, кереп, йокларга ятасың. Бу төнне син төшеңдә сөйгәнеңне күрәчәксең...*
> «

***Сәдәп фалы.*** Моның өчен берничә ак һәм кара төстәге төймә-сәдәпләр алалар. Аларны бер учка каты итеп йомарлап, икенче кулны, учын аска каратып, фал ачыла торган кешенең башына куялар. Фалчы эчтән генә: «Кайгысы капланып төшсен, бәхете тәгәрәп китсен», – дип укынып, сәдәпләр йомарланган, бармаклары аска каратып тотылган учын бушатып җибәрә...

Төрле якка чәчелеп киткән сәдәпләргә карап түбәндәгечә юрыйлар:

Сәдәпләр нык чәчелеп китсә – бу кешенең уйлары таркау, ният-хыяллары «утырмаган», күңеле иләс-миләс була.

Сәдәпләр бер урынгарак ятса – фикере төпле, максаты нык, ният-хыяллары таза, ихтыяр көче җитәрлек.

Бер ак сәдәп читкәрәк тәгәрәп китсә – бәхетен читтән табар. Кыз-кыркын булса – кияве читтән килә.

Кара сәдәп читкәрәк тәгәрәсә – чит җирдә бәхетсезлек сагалап тора. Яисә: кияүгә читкә китәчәк, әмма бәхетсез булачак.

Кара сәдәп капланып төшсә – бәхетсезлеге, кайгы-борчуы үтә торган, вакытлыча. Әмма килүе – котылгысыз.

Кара сәдәп белән ак сәдәп бер-берсенең өстен япса – кайгы да, шатлык та бер җирдән килер; кайсы сәдәпнең өстә ятуына карап, юрыйлар: карасы өстә булса – кайгы шатлыкны басып

китәчәк, ак сәдәп өстә булса – шатлык кайгыны җиңәчәк, оныттырачак.

Кара сәдәп йөзе белән ятса – мәңгегә бәхетсез булып калыр.

Ак сәдәп белән кара сәдәп янәшә ятса – кайгы белән шатлык гомере буе озатып барачак.

Кара сәдәпләр бер якка, ак сәдәпләр икенче якка тәгәрәп китсәләр – кайгы бер яктан, шатлык икенче яктан килер.

Сәдәпләр өчпочмак рәвешендә ятып, уртада ак сәдәп калса – бәхетле мәхәббәт иясе.

Уртада кара сәдәп калса – сөюе бәхетсез бетә.

Сәдәпләр тезелеп ятсалар – юлга. Тезем очында нинди сәдәп ятуына карап, бу юлның бәхет яки бәхетсезлек белән бетүен юрыйлар: ак сәдәп – бәхеткә, кара сәдәп – бәхетсезлеккә.

Сәдәпләр дүртпочмакланып ятсалар – уңышка, иминлеккә, нык тормышка.

Сәдәпләр түгәрәкләнеп ятсалар – тормышы, яшәеше бөтенәер, бәхете түгәрәкләнер... һәм башкалар.

Сәдәп фалының коллектив юрамышы да бар. Бу очракта фал ачучы, төрле төстәге төймәләр сайлап алып (алар, гадәттә, җыелган кеше санынча була), учына йомарлап кыса. Алдан һәр кешенең үз сәдәбе билгеләнә. Фалчы икенче кулына пычак тота. Кавырсын төймәләрнең дә, пычакның да магик көче, егәрлеге бар, дип ышанганнар. Бу очракта сәдәп җир маен (яки канын) белдерсә (нефть), пычак аның тәнен, сөяген символлаштыра (руда). Шулар ярдәмендә космос белән элемтәгә кереп, кешеләрнең язмышын билгеләп була, дип уйлаганнар.

Фалчы учын аска каратып тота. Үзалдына белгән догаларын укый. Бераздан пычакны алга сузып тота да, аның йөзенә учындагы төймәләрне коя башлый... Төймәләрнең ничек, кая, ни рәвешле төшүенә карап, һәр кешенең алдагы язмышын билгеләп була, имеш.

Төймә үз иясеннән читкә тәгәрәп китсә – юл көтелә яки кияве читтән булачак.

Төймә үз иясе янына тәгәрәп килсә – ялгыз калачак, үзе генә яшәячәк.

Төймәсе капланып төшсә – бәхете килделе-киттеле булачак.

Кайчакта карышлап та үлчиләр:

Ике карыш читкә китсә – ике елдан кияүгә чыга.

Өч карыш читтә – өч елдан һәм башкалар.

Фаллар ачканда татарлар арасында йөзек актив кулланыла. Борынгы милли йолаларның берсе булган ***Йөзек фалы*** бүгенге көндә кайбер төбәкләрдә әле дә очрап тора.

Яшьләр, бергә җыйналып, тирән тәлинкәгә, табакка йә чиләккә су салганнар, шул суга йөзекләр төшерелгән. Савыт каплангач, берәр җыр башкарылган. Уенны алып баручы (фал ачучы), су эчендәге йөзекләрне бераз бутаганнан соң, берсен тартып чыгара. Кем йөзеге чыкса, җыр шул кызга юралып җырланган була. Бу текстта, мәсәлән, бер агай телгә алына:

*Нардуганым нарына,*
*Бакма кеше ярына;*
*Кеше яры яр булмас,*
*Үз яр гына ят булмас.*

*Кара тавык кытныйдыр,*
*Мая салма келидер;*
*Күрше кызын мактыйлар,*
*Агай алма келидер.*

*Ай ындырчы, ындырчы,*
*Сугып ботын сындырчы;*
*Өйдән-өйгә йөргәнче,*
*Мыекларың кырдырчы.*

*Тышта буран бурыйдыр,*
*Киндер урыным черидер.*
*Молодецым, яшь купецым*
*Кайсы илләрдә йөридер?*

*Нардуганым нар булсын,*
*Эче тулы нур булсын;*
*Нардуган көен кем көйләсә,*
*Ул дәүләтле, бай булсын!*

Йөзек иясе, янәсе, әнә шул телгә алынган агайга барырга тиеш була.

Икенче бер текстта сүз «чит җиргә төшкән кыз» турында бара. Бу очракта, йөзек иясе дә чит җиргә кияүгә чыгарга тиеш, дип фараз кылына:

*Кыйгак-кыйгак диеп ни кычкыра?*
*Сазлыкларга төшкән каздыр ул;*
*Аулак җирдә сулыгып кем соң елый?*
*Чит җирләргә төшкән кыздыр ул.*

Йөзек фалы йоласында җырланган җырларның исәбе-хисабы юк. Кайчагында уйлап та куясың: монда багучылык йоласы, күрәзәлек әһәмиятлеме, әллә шул искиткеч моңлы, мәгънәле халык җырларына салынган хис-тойгылар мөһимрәкме? Менә тагын берничә шундый багу җыры. Алар да судан чираттагы йөзекне алыр алдыннан җырланган...

*И айларда гына, айларда,*
*Яшел хәтфә бүрек байларда.*
*Ходай безне кавыштырыр әле*
*Җир җиләге пешкән айларда...*

*Кыр үрдәге оча күл күреп,*
*Былбыл кошлар оча гөл күреп.*
*Җаныкаем белән без икебез*
*Сөйләшербез микән бер күреп?..*

Яисә:
*Нардуганның нары бар,*
*Мичтә пешкән тары бар.*
*Бу кешенең югары очта*
*Өзелеп сөйгән яры бар...*

Гомумән, йөзек фалларын башкарганда, кызлар язмышына багышланган җырлар башкарылган. Йола вакытында кайгы белән өмет катыш көлкеле, шаян җырлар да җырланган.

Йөзек фалында, җырлардан башка, теләкләр, ниятләр генә дә әйтелгән: кияүгә чыга, гашыйк була, читкә китә, хат ала, сөйгәне тәкъдим ясый, кунакка бара, бүләк ала һәм башкалар. Элегрәк мондый теләкләрнең махсус калып сыйфатындагылары да йөргән: «Нардуганым нарына, бакма кеше ярына», «Нардуганым нар төсле, матур ярлар бар төсле» һәм башкалар. Теләкләрдән күренгәнчә, бу фал ачулар, багуюраулар, гадәттә, Нардуган бәйрәме көннәрендә (21-22 декабрь) башкарылган. Изге вакыт, изге көннәр бит, теләкләрнең тормышка аша торган вакыты...

Шунысы да мәгълүм, «Йөзек фалы» вакытында суның чисталыгы, изгелеге мөһим шарт булган. Мәсәлән, Чистай керәшеннәрендә егетләр-кызлар, «Нардуган өе»нә җыелышып, гаиләдәге баш бала белән төпчек баланы бәкедән су алып кайтырга җибәргәннәр. Бәкедән суны балта белән кояш уңаена сызыклап алганнар. Кайтканда сөйләшмичә, артка әйләнеп карамыйча кайтканнар. Шулай алып кайтылган су тылсымлы, серле көчкә ия дип ышанганнар.

Кайбер төбәкләрдә суны ялгызак кыздан алып кердереп, йөзекне дә шул ялгыз үскән кыздан алдырганнар.

Кайчакта «йөзек салу» йоласын (бу фалның шундый атамасы да бар) мунча алдында да башкарганнар.

Йөзекне өч мәртәбә алып сынагач, суны яңартырга кушканнар. «Сынау үткән» суны кояшка каршы чиста җиргә түккәннәр.

> «
> *Кавырсын төймәләрнең дә, пычакның да магик көче, егәрлеге бар, дип ышанганнар. Бу очракта сәдәп җир маен (яки канын) белдерсә (нефть), пычак аның тәнен, сөяген символлаштыра (руда).*
> «

Татарларның ***Кашык фалы*** да шуңа охшаган. Икенче төр фалларга тагын ***Көзге фалын, Читән фалын, Йомырка фалын*** кертергә мөмкин.

Соңгысы – чәчү башланган сәгатьтә сынала торган фал. Чәчү алдыннан күп итеп йомырка пешерәләр. Аны басуга алып чыгып, тубалга салынган орлык белән бергә буразнада чәчеп йөриләр. Арттан ияргән бала-чагалар ул йомыркаларны җыеп баралар.

Беренче җыелган өч йомырка белән фал ачалар. Балалар кулыннан алып, әрчеп карыйлар: әгәр йомырка эчендә буш урын күп булса – иген уңмый, буш урын азрак булса – уңыш уртача була, бушлык бөтенләй булмаса – иген уңышы күп булачак, икмәккә тамак тук булачак, имеш.

Авыл халкын «Чәчүгә кайчан төшәргә?» дигән сорау гел борчып торган. Бу хакта хәбәрдар булу өчен еш кына ***Каз күкәе белән фал ачу*** йоласын кулланганнар. Моның өчен казның яңа гына салган беренче өч йомыркасын (сирәк кенә беренче, икенче һәм иң соңгы йомырканы) алганнар. Һәрберсен үлчәп чыгалар. Әгәр беренче йомырка соңгы икесеннән авыррак була икән, чәчүгә иртәрәк төшәргә; әгәр икенче йомырка авыррак икән, чәчүгә таман гына (бик иртә дә түгел, бик соң да түгел) төшәргә кирәк. Ә инде өченчесе беренче икесеннән авыррак булып чыкса, чәчүгә соңрак төшәргә киңәш итеlә.

# Милли уеннар – халкым мирасы

*Фәния ХӘНӘФИЕВА,*
*Арча, Кушлавыч авылы клуб мөдире*

**Уеннар – халык иҗаты җимеше. Нинди генә уенны алма, аның эчтәлегендә борынгы әби-бабаларыбызның шөгыльләре, тормыш-көнкүрешләре чагылыш таба.**

Уеннар – тәрбия чарасы да. Алар баланың шәхес булып формалашуына зур йогынты ясый, психик үсешенә ярдәм итә. Шулай ук балаларда дуслык, иптәшлек, гаделлек, зирәклек, тапкырлык, җитезлек кебек гүзәл сыйфатлар тәрбияли.

Халкыбызның милли уеннары тел байлыгын үстерүгә, аны баетуга да шактый өлеш кертә. Җырлы-биюле, түгәрәкле уеннар балаларның зәвыгын арттыра, әхлакый һәм эстетик яктан тәрбияләүгә булыша.

Мин бүген сезгә берничә уен тәкъдим итәм.







**«МӘЛИКӘ» УЕНЫ**

Уенның тәртибе болай. Бер баланың күзен бәйләп уртага утырталар, ә калганнары кулга-кул тотынып түгәрәктә җырлап әйләнәләр.

Утыр, утыр Мәликә,
Алмагачның төбенә.
Кем утырган каршыңда,
Әйтеп бирче тиз генә.

Җыр тәмамланганнан соң, күзе бәйләнгән уенчы каршына түгәрәктәге икенче бер баланы утырталар. Ул аны тотып карап, исемен әйтергә тиеш була. Әгәр дә белми икән, «җәза» бирелә. Белсә, аның каршында утырган бала белән урыннарын алмашалар. Уен шул тәртиптә дәвам итә. Бу уен балаларда игътибарлылыкны, сизгерлекне тәрбияли.

**«ҖИР-СУ» УЕНЫ**

Әлеге уенны без яшь вакытта көтү каршыларга баргач, бик яратып уйный идек. Бер малай чыбыркысын җиргә сузып сала, ул «җир-су» була. Барлык балалар чыбыркы өстендә басып торырга тиеш. Алып баручы уен тәртибе белән таныштыра. Алда – су, артта – җир. «Су» дигән команда бирелсә, алга сикерәләр, «җир» булса – артка. Әгәр дә «җир-су» дип әйтелә икән, чыбыркы өстендә калалар. Хата җибәрүчеләр уеннан чыга бара. Иң ахырга калучы җиңүче була. Бу уенда да баланың җитезлеге, игътибарлылыгы тикшерелә.

**«ЯУЛЫК БИРЕШ» УЕНЫ**

Уенчылар түгәрәккә басып, бер якка биеп әйләнәләр. Уртада яулык тоткан уенчы аларга капма-каршы якка бии. Аннары ул биючеләрнең берсе каршында туктап, яулыкны аңа бирә һәм икәү парлап бииләр. Туктагач, яулык биргән кеше түгәрәккә баса, алганы түгәрәк буенча капма-каршы якка биеп, теләгән кешесенә яулыгын бирә, шулай биергә чакыра. Уен шул тәртиптә дәвам итә.

**«МИНЕМ ИСЕМ СИНДӘ ТҮГЕЛМЕ?» УЕНЫ**

Әлеге уенда күбрәк яшьләр катнаша. Уйнаучылар саны парлы булырга тиеш. Бер якта егетләр, икенче якта кызлар утыра. Так калган кеше кызларга егетләрнең исемнәрен колакларына пышылдап әйтеп чыга. Исемнәр буталып әйтелә. Егетләр берәм-берәм кызлар каршына килеп: «Минем исем синдә түгелме?» – дип сорый. Әгәр дә аның иseме түгел икән, кыз аңа: «Юк шул, синең исемең миндә түгел», – ди. Егет кире үз урынына барып утыра. Аннан икенче егет килеп сорый. Шулай үз исемнәрен тапканчы эзлиләр. Әгәр егет үз исемен таба икән, кыз аның урынына, ә егет кыз урынына күчә. Шулай итеп, егетләр кызлар ягына, кызлар егетләр ягына күчеп бетәргә тиеш. Ә иң ахырга калган пар, иң бәхетле пар була. Исем эзләмичә генә аларны парлап биетәләр, йә җырлаталар, йә йолдыз санарга чыгарып җибәрәләр. Аннан соң егетләргә кызлар исемен әйтәләр. Уен кабат шул тәртиптә дәвам итә.

Халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, уеннары сәхнәдә генә калмыйча, чынбарлыкта да югалмасыннар, мирас булып, буыннан-буынга саклансыннар иде.

Фоторәсемнәр Арча районы Мәдәният йорты архивыннан

# Гатаулла бай йорты – Әтнәнең символы



Әтнә Туган якны өйрәнү музее директоры Әлфинә Мөхәммәтҗанова

Әтнә төбәге республикада территориясе ягыннан әллә ни зур булмаса да, ул үзенең хезмәт сөюче, тырыш, батыр кешеләре, аларның матур эшләре, күренекле гыйлем ияләре, сәнгать әһелләре, язучы-әдипләре белән дан тота. Шушы районда өч музейның эшләп килүе үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Музейлар – үткән белән киләчәкне тоташтыручы күпер. Биредә халыкның тарихы, рухи мирасы булып торган экспонатлар – иске кульъязмалар, әби-бабаларыбызның кул эшләнмәләре, тормыш-көнкүрештә кулланылган әйберләр, фоторәсемнәр саклана. Музейлар эшчәнлеге тәрбия чарасы да булып тора. Бүгенге көндә безнең районда 3 музей эшли: Әтнә туган якны өйрәнү музее, Күлле Киме авылында – Сибгат Хәким музее һәм Комыргуҗада – Шиһабетдин Мәрҗани музее. Соңгы икесе райондагы төп музейның филиаллары санала.

Әтнә Туган якны өйрәнү музее 2010 елда оештырылды. Аның бинасы ерактан ук үзенә җәлеп итеп тора. Андагы экспонатлар районыбызның барлык авыллары халкыннан клуб, китапханә хезмәткәрләре тырышлыгы белән җыелды. Бүгенге көндә төп фондта барысы мең ярымнан артык экспонат исәпләнә. Музей фондында төрле җыелмалар тупланган. Биредә, мәсәлән, кырлы бәләк, күмер үтүкләре, агач кисмәк, ипи чаралары (ипине әвәләгәч, кабарту өчен салып куя торган чыбык яки









агач савыт), самавыр, керосин лампалары, стена сәгатьләре, кызыл башлы сөлге, чигүле ашъяулыклар, күкрәкчәләр һәм аяк чолгаулары бар. XX гасыр башы йорт эче күренеше игътибарга лаек: акбур белән агартып куелган мич – өйнең күрке. Аның янында торган күмер савыты, морҗалы самавыр – гадәти тормыш рәвешен күрсәтә. Тәрәзәләрдәге ак кашагалар – тәрәзә пәрдәләре, сәке кырыена чигелгән «итәк» куелып, сәке йөзлегенә суккан палас җәю дә өйгә үзенә күрә җылылык өсти. Көнкүреш һәм хезмәт кораллары, йорт җиһазлары, савыт-сабалар, хатын-кызларның һәм ир-атларның өс киемнәре – барысы да әби-бабаларыбызның тормышын хәтерләтә.

Музей экспонатлары арасында төрле зурлыктагы киле, гөбе, үргән кәрҗиннәр, балчык чүлмәкләр, самавырлар җыелмасы аерым киштәдә урын алган.

Сугыш чоры һәм сугыштан соң кулланылышта булып, хәзерге көндә Гатаулла байның йорты янына урнаштырылган кабинасыз трактор да күпләрнең игътибарын җәлеп итә. Туку станогы, кул белән такта яра торган пила да яшь буын күрмәгән эш коралы булып тора. Шулай ук, тормыш иптәше Нурия апа Халикова тапшырган, якташыбыз шагыйрь Хәкимҗан Халиковның китапханәсе һәм шәхси әйберләре дә музеебызда лаеклы урынын алды. Музей XIX-XX гасырда үзебезнең җирлек кешеләренең









тормыш-яшәешен, тарихын, төбәгебездә, илебездә булган вакыйгаларны чагылдыра.

Казан арты элек-электән мул һәм житеш тормышлы байлары, сәүдәгәрләре, осталык һәм зәвык белән бизәлгән күп катлы матур, мәһабәт йорт-жирләре, каралты-куралары белән танылган төбәк булган. Чыганаклардан күренгәнчә, бу жирлектә татар милли архитектурасы XV-XVI гасырларда ук югары дәрәжәдә үсеш алган булган. Андый корылмалар үзләренең төзелеше ягыннан борынгы болгар архитектурасы традицияләренә барып тоташа.

«Әтнә – жәүһәр» дигән гыйбарә буш урында барлыкка килмәгән. Билгеле булганча, Олы Әтнә байлар авылы дип саналган. Кара байлар белән беррәттән, беренче һәм икенче гильдия сәүдәгәрләренең саны да шактый булган. XIX гасырда яшәгәннәрдән, без Гатаулла байны искә алабыз, чөнки аның йорты һәм хужалык корылмалары сакланган һәм яңартылган. Гатаулла Даутов икенче гильдия сәүдәгәре рәтенә кергән. Аның таштан салынган кибетләре булган. Ул мануфактура һәм бакалея товарлары белән сәүдә иткән. Әллә ни гыйлеме булмаса да, бу сәүдәгәрнең ат олаулары Олы Әтнәдән Шәкәнәч авылына кадәр (чама белән 3 километр ара) сузылган. Байның авыл халкына бик ярдәмчел булуы хакында телдән-телгә сөйләнелгән: уңышлы сәүдәдән соң, керменең бер өлешен ярлыларга өләшә торган булган.

Гатаулла бай йорты 1895 елда – XX гасыр башында салынган. Хәзер биредә Әтнә туган якны өйрәнү музее урнашкан. Койма белән әйләндереп алынган комплекс байлар яшәгән йорттан, сарайдан, келәттән, мунча, кибеттән, ике капкадан тора. Ике катлы йорт бинасы хач формасында нык һәм төз бүрәнәләрдән төзелгән, тышкы һәм эчке яктан бик үзенчәлекле итеп эшләнгән, милли стильдә нечкә зәвык белән бизәлгән. Мунчасы – йортның артына, ә кибете, урам яктан керә торган итеп, капка янына салынган.

Өйнең алгы ягында уепсырлап бизәкләгән терәкләр белән ике керү юлы. Йортның һәр ягында – өчәр тәрәзә, төп фасадның каршысында – дүрт тәрәзә уелган. Аларның йөзлекләре бизәкләп эшләнгән. Төп фасадтагы икенче катның өстендә өч ягы буйлап сузылган агач терәкле жиңел верандага охшашлы кырып эшләгән, бизәкле аркалы зал урнашкан. Биредә кызлар өчен жәйге бүлмә булган.

Икенче катка кырып бизәлгән баскыч буйлап күтәрелсәң, өйнең ак өлешенә һәм кызлар бүлмәсенә килеп чыгасың. Алар иркен һәм якты. Йортның беренче катында кара өй, келәт, чолан, кызлар һәм карчыклар бүлмәсе, сәке урнашкан. Икенче каттан аермалы буларак, тәрәзәләре аз һәм кечерәк булу сәбәпле, астагы бүлмәләр караңгы, түшәмнәре тәбәнәк булган.

Гатаулла бай йортын районыбыз халкы яхшы белә. Кунакка килүчеләргә дә аны күрсәтәсебез, аның белән горурланасыбыз килә. Безнең алдыбызда, тарихыбызны саклау, киләчәк буыннарга житкерү бурычы тора.

Бүгенге көндә музейда реставрация эшләре бара. Бу комплекс, Татарстан Республикасының Мәдәни мирас-истәлекләре җыелмасына кертелеп, архитектура байлыклары берсе, Әтнәнең символы булып тора. Татар агач архитектура үрнәге итеп, бу йортның макеты Милли музейга куелган. Хәзерге вакытта йорт бинасы дәүләт тарафыннан саклана.

**Гөлсинә ХӘКИМУЛЛИНА,**
**Әтнә, Күлле Киме авылы,**
**Сибгат Хәким музееның әйдәп**
**баручы методисты**

Фоторәсемнәр Әтнә Туган якны өйрәнү музее архивыннан




«Аулак өй» күренеше

# *Милли мирас өләшүче «Хәзинә»*

Мин еш кына авыл мәдәният учакларында эшләп килүче иҗат коллективлары белән фольклор фестиваль-бәйгеләргә йөрим. Күрәм, фольклор күренешләрдә күпчелек өлкән буын



«Мунча себеркесе әзерләү» күренеше

вәкилләре катнаша. Шуларның берсендә, районыбызда яшьләрдән генә торган фольклор коллективы оештырырга кирәк, дигән фикергә килдем. Чөнки Мәдәният йортыбызда яшьләр күп, әйткәч, алар да бик теләп риза булдылар. Шулай итеп, 2023 елда Арча районы Мәдәният йорты каршында «Хәзинә» фольклор коллективы туды. Сценарий язганда өлкән буынга – әби-бабайларга мөрәҗәгать итәбез, китаплардан эзләнәбез, күбесенчә безнең якка хас булган йола һәм гореф-гадәтләрне кулланабыз. Репертуарны сайлаганда яшьләргә кызык һәм якын булган күренешләрне алырга тырышабыз.

Эшчәнлегенә бер ел булмаса да «Хәзинә» фольклор коллективы ел дәвамында күп кенә бәйге-фестивальләрдә катнашырга өлгерде. Чыгышларыбызны халык шулкадәр яратып



**«Каурый бәйрәме» күренеше**




«Студентларның бәрәңге алу чоры» күренеше

кабул итте. Казанда Сабантуй бәйрәмендә, «Бөтенроссия кыр көне – 2023» агросәнәгать форумы күргәзмәсендә чыгыш ясадык, ТВ сюжетында төштек. Мари Эл республикасында һәм Кайбыч кебек Татарстан районнарында узган фольклор фестивальләрдә алдынгы урыннарны яуладык.

Бүгенге көндә «Хәзинә» коллективы Арча районында уза торган чараларда да актив катнаша, борынгы гореф-гадәтләрне һәм йолаларны саклау, үстерү буенча зур эш алып бара. Коллектив яшьләрдән тора, биредә 18дән алып 39 яшькә кадәрге арчалылар йөри. Коллективның чыгышларын, яшьләр белән бер дулкында булган, баянчылар Вагыйз Әглиуллин белән Фәнис Тимашев бизи.

«Хәзинә»нең репертуарында – «Кичке уен», «Аулак өй», «Никах йоласы», «Көтү куу», «Сабантуйга бүләк җыю», «Студентларның бәрәңге алу чоры», «Каурый бәйрәме» кебек күренешләр бар. Бүгенге көндә коллектив, «Пушкин картасы» проекты кысаларында, укучыларга милли мирасны җиткерергә омтылып, мәктәпләрдә чыгыш ясый. Мәсәлән, «Аулак өй» күренешен Арча районының барлык уку йортларында – авыл мәктәпләрендә куеп чыктык.

Хыялыбыз – фольклор бәйгеләрдә катнашып, исемебезне таныту, районыбызда сакланып калган гореф-гадәтләрне, йолаларны халыкка җиткерү.



«Көтү куу» күренеше

**Ләйлә ХӘКИМОВА,**
**Арча районы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе**

Фоторәсемнәр Арча районы Мәдәният йорты архивыннан

# Фольклористикада – халык әкиятләре




Татар халык иҗаты. 3 т.: Әкиятләр (Хайваннар турындагы һәм тылсымлы әкиятләр) / [төз. текст., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. И. Г. Закирова]. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2023. – 487 б.

**Татар халык әкиятләре академик 25 томлык «Татар халык иҗаты»ның алты китабында урын алды. Томнарның әкиятләргә багышланган беренче китабында хайваннар турындагы һәм мифологик мотивларга нигезләнгән, борынгы ышануларны саклаган тылсымлы әкиятләр тәкъдим ителә. Әкиятләргә багышланган икенче һәм өченче китапларда – тылсымлы әкиятләр, дүртенче китапта тылсымлы әкиятләрнең бер төрен тәшкил иткән батырлар турындагы әкиятләр урын алды. Бишенче һәм алтынчы китапларда көнкүреш әкиятләре тупланды.**

**...Әкият – гарәп теленнән кергән термин, хикәят (хикәя) сүзенең варианты булып, сүзнең күп кенә халыкларда очравы һәм мәгънәсе киңәюе аның борынгы кыпчак дәверендә үк таралганлыгын дәлилли. Мәсәлән, чувашларда экият – такмак, мариларда äкият – уйдырма, удмуртларда акият – әкият һәм уйдырма мәгънәләрендә кулланыла. Әкият терминының бездә кабул ителгән мәгънәсенә синоним рәвешендә жанрның башка атамалары да бар. Мәсәлән, татар халкында мәсәл яки мәсәлә, йомак дигән атамалар да очрый. Төрек халкы да әкият жанрын масал дип атый. Чувашлар юмах йомак дигән термин кулланалар. Борынгы йомак сүзенең татарларда әкият сүзе белән параллель һәм актив кулланылуына алдавыч әкиятләрдә сакланган «әкиятем-йомагым» дигән гыйбарә ишарәли.**

# ХАЙВАННАР ТУРЫНДАГЫ ӘКИЯТЛӘР

**Хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр һәм алар белән бәйле вакыйгалар аша кешелек җәмгыятен тасвирлауга корылган әкиятләрне хайваннар турындагы әкиятләр дип атыйлар. Татар халык әкиятләре арасында хайваннар турындагы әсәрләр сан ягыннан күп түгел. Әлеге әкиятләрнең төп геройлары – җәнлекләр, кошлар, йорт хайваннары һәм кыргый хайваннар. Алар үзләрен кеше кебек тоталар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне кабатлыйлар, сөйләшәләр, аралашалар, кунакка баралар, дуслашалар, дошманлашалар.**

## Сауны хаста күтәрер

Хайваннар патшасы Арыслан авырып ята икән. Арысланның хәлен белергә бөтен хайваннар килеп беткәннәр, ди, ә хәйләкәр Төлке һаман юк, ди. Төлке килмәгәч, Бүре Арысланга барып әләкләгән, ул сине санламый, дип. Бүренең әләкләгәнен Төлке бер кырыйдан гына карап торган икән.

Бервакытны Төлке килеп керүгә, Арыслан ачуы килеп, гайрәтләнеп аның янына килә дә:

– Әй хаин, син нигә болай соңга калдың? – ди.

– Мин синең авырганыңны ишеттем дә сиңа дару эзләдем, – ди.

– Соң, дару таптыңмы? – ди.

– Таптым, – ди. – Бүренең арт сыйрагын кисеп ашасаң, синең авыруың бетәр, – ди.

Арыслан шунда ук Бүрегә ташлана да арт сыйрагын йолкып ала. Хәзер Бүре аксап китә инде. Йөри торгач, Бүре тагын Төлкегә очрый.

– Минем эш харап, – ди, – аягым авырта, берәр дару белмисеңме, – ди.

– Беләм, – ди, – койрыгыңа кызау бәйләп, бәкегә тыгып утырсаң, балыклар эләгер, – ди. – Шул балыкларны ашасаң, аягың төзәлер, – ди.

Шулай итеп, Төлке өйрәткәнчә, кызау бәйләп, койрыгын бәкегә тыгып утыра бу. Койрыгы шытыр-шытыр килгән саен Төлке әйтә: «Тимә, тимә, бераз торсын әле, күбрәк керсен», – ди.

Иртә белән хатыннар суга килсәләр, койрыгы бозга каткан Бүрене күреп, көянтәләр белән кыйный башлыйлар. Кыйный торгач, Бүре койрыгын өзеп кача, ди.

Йөри-йөри Бүре тагын әлеге Төлкегә очрый.

– Эшем начар, – ди Бүре, – аягым авырта, койрыгым да өзелде, – ди, – син берәр дару белмисеңме? – ди.

– Беләм, – ди, – әнә шул тау башына менсәң, шунда дару табарсың, – ди.

– Син миңа күрсәт инде ул даруны, – ди Бүре.

– Күрсәтер идем дә, – ди Төлке, – минем вакытым юк, – ди. – Инде өстеңә утырып, тиз генә барып кайтсак кына, – ди.

– Әйдә утыр минем өстемә, – ди, – тиз генә барып кайтыйк, – ди.

Төлке Бүре өстенә утырган да: «Сауны хаста күтәрер, сауны хаста күтәрер», – дип җырлап бара, – ди.

Әле дә булса шулай җырлый-җырлый дару эзләп йөриләр, ди, болар.

## Кола Ат

Яшәгән, ди, булган, ди, Карт белән Карчык. Аларның булган, ди, бер кола Атлары. Яхшы ат инде – көчле дә, матур да. Бервакыт карт бу атны кырга утларга чыгарып җибәргән. Кырда йөргәндә берзаман күрә кола Ат: аның каршысына бер Барс йөгереп килә. Кола Ат куркып кала инде, әмма сиздерми – Барстан сорый:

– Син кем буласың? – ди.

– Мин – ала Барс, барлык җәнлекләрнең башлыгы булам, – ди. – Ә син кем?

– Мин – кола Ат, – ди бу, – барлык терлекләрнең башлыгы булам.

Ала Барс бүтән башлыкны очраткач куркып кала һәм әйтә моңа:

– Ә шулай да мин – синнән зуррак башлык, – ди.

– Юк, мин синнән зуррак! – ди кола Ат.

Алар шулай озак кына бәхәсләшкәч, ниһаять, кола Ат әйтә:

– Әйдә, синең белән көч сынашыйк, – ди.

– Әйдә, – ди Барс. – Ләкин без көчебезне ничек сынашырбыз соң?

– Менә ничек, – ди кола Ат, – кем дә кем таштан очкын чыгара – шул көчлерәк була.

Барс килешә һәм беренче булып көчен күрсәтә башлый. Ташка ул аяклары белән бәрәтибә, әмма файдасыз: очкын чыкмый да чыкмый.

Шуннан соң кола Ат ташка үзенең дагаланган тояклары белән китереп типкән икән, таштан бер көлтә очкын чәчелеп киткән.

Барс очкыннарны күргән, элеккедән дә катырак куркып, бар көченә йөгереп качып киткән, ди.

## Курбала

Борын-борын заманда бер Карт белән Карчык торган. Аларның балалары булмаган.

Беркөнне Карт итлектән он себереп керә. Карчыгы онны иләп, каймакка басып, кур ясый. Кур әзер булгач, бала башы ясый, аннан аякларын, кулларын ясый да тәрәзәгә киптерергә куя.

Кур кибә, тәрәзәдән сикереп төшә дә бала булып йөгереп китә. Йөгерә-йөгерә урманга җитә. Урманга барып керсә, Куян очрый.

Куян әйтә:

– Мин сине ашыйм, – ди.

– Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлармын, – ди Курбала.

– Җырла, – ди Куян.

– Мин итлектән себерелгән,
Каймакка басылган,
Курдан ясалган;
Башлыктан киттем,
Бабайдан киттем,
Синнән китәм дә китәм, – ди.

Куяннан качып китә. Бара-бара Аюга очрый. Аю әйтә:

– Мин сине ашыйм! – ди.

– Син мине ашама, – ди Курбала, – мин сиңа җыр җырлармын, – ди.

– Җырла! – ди Аю.

– Мин итлектән себерелгән,
Каймакка басылган,
Курдан ясалган;
Башлыктан киттем,
Бабайдан киттем,
Куяннан киттем,
Синнән китәм дә китәм, – дип качып китә.

Бара-бара Төлкегә очрый.

– Мин сине ашыйм! – ди Төлке.

– Син мине ашама, мин сиңа җыр җырлармын, – ди Курбала.

– Җырла, – ди Төлке.

– Мин итлектән себерелгән,
Каймакка басылган,
Курдан ясалган;
Башлыктан киттем,
Бабайдан киттем,
Куяннан киттем,
Аюдан киттем,
Синнән китәм дә китәм, – дигән икән.

Төлке әйткән:

– Һай, матур да җырлыйсың икән. Яле, якынрак килеп, тагын бер җырлап бир әле, – дигән.

Курбала, якынрак килеп, тагын бер җырлаган икән, Төлке аны ашаган да куйган.

## Чыгымчы ат

Бер авылда ике дус яшәгән. Аларның берсе җәй башында сугым (суярга ат) ала икән дә, җәй буе крестьян эшендә эшләтеп, көз көне атын суя икән. Сугымның ярты итен сата, яртысын үзләренә ашарга калдыра. Саткан итнең акчасын яз көне тагын ат алырга дип җыеп куя икән.

Берзаманны сатып алган атын җигә дә сукага китә бу. Җирне сукалый башлагач, аты тыңламый башлый, тибенә. Атка сукса, тибеп тәртәне сындырырга мөмкин, сукмаса, бармый.

Шулай аптырап торганда, кыр башыннан моның дусты узып бара икән. Дусты килә дә сораша башлый:

– Хәлең ничек? – ди.

– Күрәсең бит хәлемне:
Атым бармый,
Сукам керми,
Өйгә кайтсам,
Хатыным ашарга бирми.
Нишләргә инде миңа хәзер бу ат белән? – ди.

Дусты әйтә моңа:

– Син аңа
«Таугa менми,
Менсә төшми,
Камчыны сөйми,
Тәпәчсез йөрми» дип әйт, аннан китәр ул, – ди.

Дөрестән дә, шулай дип әйткәч, моның аты чабып киткән, ди.

# ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЛӘР

**Яхшылык явызлыктан өстен торган һәм дөреслек һәрвакыт җиңеп чыга торган дөнья бар. Бу – тылсымлы әкиятләр дөньясы. Аның геройлары әкият кануннары буенча яши, тыңлаучыларны яки укучыны дөньяда һәр явызлыкны җиңеп чыгарлык көч булуына ышандыра.**

## Айсылу

Әүвәл заманда бер хатын булып, аның Айсылу исемле бердәнбер кызы булган. Бервакыт күрше кызлары аны су керергә чакырганнар. Айсылу күрше кызлары белән бергә барып җитә алмаган.

Айсылу үзе генә су янына барып җиткәндә, теге кызлар судан чыгып киләләр иде. Ул, ялгызы су кереп, кырыйга киенергә чыкканда, күлмәгенә бер зур Елан ятканын күрде һәм, бер таяк алып, еланны сугып үтерергә теләде. Елан, телгә килеп:

– Әгәр син миңа кияүгә килергә разый булсаң, мин синең күлмәкләреңне бирәм, әгәр разый булмасаң, хәзер үтерәм, – диде.

Айсылу никадәр котылырга теләсә дә, барырга ризалык күрсәтмичә торып, котыла алмады. Елан, Айсылуның ягымлы сүзләрен ишеткәч, күлмәкләрен биреп, бер атнага өенә кайтарып җибәрде. Айсылу кайгылы йөз белән кайтып кергәч тә, анасына ни күргәнен барын да сөйләп бирде.

Анасы:

– Бу өеңдә түгел, төшеңдә күргәннәреңдер, – диде.

Анасы ышанмаса да, кыз бик кайгыда торды.

Бер атна үтүгә, Айсылу белән анасы урам тулы еланнарның килгәннәрен күрделәр. Айсылу, куркып, чуал өстенә менеп, анасы да тәрәзәләрне томалап, үзе сәке өстенә менеп, сандык артына яшеренде. Еланнар боларның өен табып, берсе өстенә берсе үрмәләп, тәрәзәләрне ватып өйгә кереп, Айсылуны эзләп табып, алып чыгып киттеләр.

Айсылуның анасы кызының артыннан барды. Еланнар туп-туры күлгә барып, Айсылуны да суга алып кереп киттеләр. Айсылуның анасы, кире өенә кайтып: «Мин кайтканчы кызымны инде буып үтергәннәрдер», – дип, хәсрәтеннән бернәрсә дә эшләми елап утырды. Башка балалары булмаганлыктан, юатучысы юк иде.

Өч елдан соң Айсылуның анасы бер хатынның килгәнен күрде: кулында бер ир бала булып, берсен җитәкләгән иде. Хатын туры бу өйгә килеп керде. Сөйләшә башлагач, бу хатын Айсылу булып чыкты. Соңра анасы кызыннан:

– Син кайда торасың, кызым? – дип сорады.

Айсылу әйтте:

– Су патшасы булган Еланда торамын.

Анасы:

– Соң, кызым, коры җирдә торсаң яхшымы яисә суда яхшымы? – диде.

Кызы әйтте:

– Суда яхшырак.

Әнкәсе:

– Кызым, соң син анда ничек кайтып керәсең? – диде.

Кызы әйтте:

– Мин күлнең читенә барам да: «Бикбау! Мин килдем, чыгып ал», – дип кычкырам, минем тавышымны ишетеп, ул мине чыгып ала.

Әнкәсе, кызының бу сүзләрен ишетеп:

– Бу көн бездә кунып китәрсең, – диде.

Кыз:

– Мин бер генә көнгә рөхсәт алдым, – диде.

Шулай булса да, анасы бик ялынгач, кунарга булды. Болар, ятып, озак сөйләшкәннән соң, Айсылу йокыга китте. Анасы кулына балта алып чыгып китте дә, су янына барып:

– Бикбау! Мин килдем, чыгып ал, – диде.

Елан судан башын гына чыгарган иде, хатын балта белән аның башын чабып төшерде, һәм үзе өенә кайтып китте.

Иртә торып ашап-эчкәннән соң, балаларын киендереп, берсен күтәреп, берсен җитәкләп, Айсылу анасы белән саубуллашып чыгып китте. Су кырыена барып:

– Бикбау! Мин килдем, мине чыгып ал, – дип, бик озак кычкырды, судан бернәрсә дә чыкмады.

Ипләбрәк караса, су өсте кызыл кан булган, Айсылу, ирем үлгән икән инде дип, балаларына таба карап:

– Балалар, сезнең атагыз булмагач, анагыз да булмасын, – дип, улына: – Улым, син атаң өстендә карлыгач бул, кызым, син дә сандугач булып сайрап йөр, мин күке булып кычкырып йөрим, – дип, өчесе өч төрле кош булып очып киттеләр.

Әле дә булса очып йөриләр бугай.

# «Максатым – Самара татарлары фольклорын, халкыбызның борынгы киемнәрен, уен коралларын, җыр-такмакларын таныту»

*Эльмира САЙФУЛЛИНА,*
*«Бердәмлек» газетасы хәбәрчесе*

**Самараның «Заря» мәдәният сарае каршында эшләп килүче «Заман» татар балалары фольклор ансамбле бер ел элек кенә оешкан булуына карамастан, шәһәр һәм өлкә күләмендә үткән милләтара чараларның актив катнашучысы.**

– 2022 елның октябрендә кастинглар, сайлап алулар үткәрелсә, декабрь азагында без инде беренче репетициягә җыелдык. 2023 елның мартында «Заман» балалар фольклор ансамбле «Бала-фест» фестивалендә беренче чыгышын ясады. Биредә ул Самара өлкәсенең Камышлы районы Дәүләткол һәм Иске Балыклы авылларында җырлана торган халык җырларын башкарды. 2023 елның көзендә «Заман»лылар Казанда «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе уздырган «Халыклар мирасы» бәйгесендә катнашып, өч меңнән артык тавыш җыеп, «Интернет аудиториясендә иң популяр коллектив» номинациясендә җиңү яулады.



Вәсимә Фәрдиева





Бүгенге көндә коллективыбызда унбиш бала шөгыльләнә. Иң олысына – 13, иң кечесенә 5 яшь. Нәни Камилә ансамблебезнең йолдызчыгы, – ди ансамбльнең сәнгать җитәкчесе Васимә Фәрдиева.

Васимә студент елларында ук татар фольклорын, халкыбызның борынгы киемнәрен, уен коралларын, җыр-такмакларын таныту максатыннан, балалар ансамбле оештырырга хыялланa. Самара дәүләт мәдәният институтын тәмамлап, өлкә күләмендә уздырылган чаралар оештыруда катнаша, спектакльләр сәхнәләштерә. Моңа кадәр дә ул Самараның «Яктылык» мәктәбендә һәм Ялтаның (Кырым) Ренат Ибраһимов исемендәге халыкара мәктәбендә педагог-оештыручы булып эшли. Бүгенге көндә – «The players» кавер төркеме солисты.

– Ансамбль оештырганда мин татар халкының милли киемнәре белән дә мавыгып киттем. Интернетта Казанда яшәүче, табиб, татар милли костюмнар коллекционеры һәм реконструкторы Гөлшат Ногайбәкова (Шәмсетдинова) белән таныштым һәм без бүгенге көнгә кадәр хезмәттәшлектә. Аның архивындагы «байлык»



Мидхәт Әминов





бәяләп бетергесез, искиткеч! Ул безгә бик нык ярдәм итә, моның өчен мин аңа чиксез рәхмәтлемен. Гөлшат ханым татар халкының борынгы киемнәре, бизәнү әйберләре, һәрбер төймә, җөй, тукыма һәм башка элементлары турында сәгатьләр буе сөйли ала. Ә мин, үз чиратымда, аңардан ишеткәннәрне балаларга сөйлим. Алар кигән киемнәренең ни өчен нәкъ менә шундый фасонда булуын белергә, изү, хәситә, чулпы, калфак кебек бизәнү әйберләрен кадерләргә, тарихын һәм асылын аңларга, горурланырга тиешләр. Киләчәктә үзләре дә дусларына, туганнарына, балаларына бу мәгълүматны җиткерә алсыннар иде, дип тырышам. Милли хәзинәләребез югалмасын, күп көч, тырышлык белән җыелган архив материаллары буыннан-буынга күчеп, мирас булып саклансын иде.

Шәһәребездә үзебезнең «Татар үзәге»н булдыру – минем икенче зур хыялым. Иҗат төркемнәре анда репетицияләргә йөрер, костюмнарын, уен коралларын бер урында саклар иде. Шунда ук милли музей да оештырылса, кечкенә генә кинозалы да булса, татар җәмәгатьчелеге очрашулар, күргәзмәләр һәм башка чаралар уздырса, искиткеч шәп булыр иде, – ди Вәсимә Фәрдиева.

Студент елларында ук Вәсимә, этнографик эзләнүләр вакытында, шактый милли кыйммәткә ия булган экспонатлар җыя.

– Хәзерге вакытта, экспедицияләрдә тупланган такмаклар, җырлар, биюләр төшерелгән видеоларны «Самара фольклоры үзәгенә» тапшырам. Без башлаган изге эш дәвамлы булыр, дип ышанам. Самараның рус традицион мәдәнияте үзәге директоры Андрей Михайлович Давыдов белән Самараның мәдәнияте институты профессоры Тамара Ивановна Ведерниковага рәхмәт. Алар миндә милли мәдәниятебезгә мәхәббәт уяттылар һәм үземнең милләтемнең үзенчәлекләренә игътибар итәргә өйрәттеләр, – ди ул.

«Ансамблегезгә костюмнарны кем тегә?» – дигән сорауга:

– Бу четерекле эшне Самарада яшәүче профессиональ тегүче Наталья Хәйруллинага тапшырдык. Ул – Самараның рус традицион мәдәнияте үзәге хезмәткәре, тарихи костюмнарны реконструкцияләү белән шөгыльләнә. Төбәгебезнең милли костюмнары турында аннан да яхшырак белүче юктыр, мөгаен. Ул русларның гына түгел, башка Идел буе халыкларының традицион киемнәре белән дә кызыксына. Әлегә иганәчеләребез юк, киемнәр тулысынча ата-аналар акчасына тегелә, – ди Вәсимә Фәрдиева.

Халык уен коралларын, этнографик экспедицияләр вакытында, авыллардан җыюлары турында да мавыгып сөйли ул. Самавыр торбасы, кер тактасы, чиләк, агач кашыклар, шак-шок – барысы да халык музыкасы кораллары. «Заман» ансамблендә скрипкада уйнаучы Әминә дә бар. Аның белән борынгы көйләр уйнарга өйрәнәләр. Камышлы районында өч скрипкачы яшәгән. Аларны белгән кешеләр аша борынгы көйләрне ничек итеп уйнарга, скрипканы ничек итеп тотарга кирәклеген (чөнки алар җилкәгә түгел, терсәккә куеп уйнаганнар) сорашып, тамашачыга күрсәтергә әзерләнәләр.

– Этнографик сәфәрләр искиткеч файдалы, әмма күп вакытны алалар. Сәяхәт барышында тупланган мәгълүмат – онытылып барган, яки бөтенләй кулланылыштан чыккан җырлар, такмаклар, биюләр, көнкүреш кирәк-яраклары, киемнәр – татар халкының бәяләп бетергесез мәдәни мирасы. Шундый бер сәфәрдән XX гасыр башында ук юкка чыккан кыл-кубыз алып кайттык. Ул казах, башкорт, төрки халыкларының музыка коралы булып санала, бик үзенчәлекле моңга ия: ике кыллы скрипканы да хәтерләтә, думбрага да охшаш. Аны безгә Исаклыда яшәүче, борынгы уен кораллары ясаучы остаз Максим Радионов ясап бирде. Башка милли уен коралларына килгәндә, курай, кубыз, тальянка, гармун, барабан һәм думбрабыз бар. Аларның барысын да, 25 елдан артык «Идел» үзешчән ансамбль җитәкчесе булып эшләүче, Мидхәт абый Әминов җыйган. Ул безгә «Заман» ансамблен оештырырга да ярдәм итте, – ди Вәсимә Фәрдиева.

Балаларны яратуы, ансамбльгә йөрүчеләрнең күбесе туган телләрен белмәве турында да сөйләде сәнгать җитәкчесе. Әмма бернинди авырлыкларга карамастан, ярты ел дигәндә, «Заман»лылар үзләрен Самара тамашачысына танытырга да, Татарстанның халык артисты Венера Ганиева, Татарстанның атказанган артисты Илфат Шәехов кебек танылган сәнгать ияләренең, «Татарстанның мәдәният ресурс үзәге» белгечләренең югары бәясен алырга да өлгергәннәр.

– Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге этнографлары һәм белгечләре безне искиткеч җылы каршы алды, ансамбльнең чыгышын карап, алкышларга күмделәр, костюмнарына югары бәя бирделәр, – дип сөйли Мидхәт Әминов. – Без Казаннан канатланып, горурланып, яңа үрләр яуларга әзер булып кайттык. Яшь булуына карамастан, Вәсимә нинди генә эшкә алынса да азагына кадәр башкарып чыга. Олылар белән дә, балалар белән дә бик тиз уртак тел таба. Искиткеч талантлы (тавышы бик моңлы, берничә уен коралында уйный), милли җанлы, ару-талуны белмәс кеше ул. Кыска гына вакыт эчендә ансамбльне шундый дәрәҗәгә күтәрү, таныту өчен тырышлык, осталык, үҗәтлек кирәк.

Тимур Сафин фоторәсемнәре.
В. Фәрдиеваның шәхси архивыннан

# Язбикә

**Наилә Яхина көе,**
**Рәхимә Арсланова сүзләре**




*Алмачуар атында*
*Сәлам алып кошлардан,*
*Килеп җитте март аенда*
*Язбикә ераклардан.*

***Кушымта:***
*Язбикә, Язбикә,*
*Килде безгә ерактан.*

*Кояшның шаян нурлары*
*Эретте кар-бозларны.*
*Колач җәеп каршы алды*
*Яз канатлы дусларны.*

***Кушымта:***
*Язбикә, Язбикә,*
*Каршы алды дусларны.*

*Кышкы йокыдан уянды*
*Урманнар һәм тугайлар.*
*Яз җырына кушылдылар*
*Сыерчыклар, тургайлар.*

***Кушымта:***
*Язбикә, Язбикә,*
*Сыерчыклар, тургайлар.*

*Чәчәкләр кояшка карап,*
*Күтәрде дә башларын.*
*Сәлам биреп Язбикәгә,*
*Ачты нәфис таҗларын.*

***Кушымта:***
*Язбикә, Язбикә,*
*Ачты нәфис таҗларын.*



Фоторәсемдә Чистай районы Гаделша мәктәбе укучылары

**Кыстыбый бик тәмле һәм туклыклы, шул ук вакытта әзерләргә җиңел булган татар милли ризыгы. Кайбер якларда аны күзикмәк, якмыш, җакмыш, кыстымбый да диләр. Гадәттә кыстыбыйны төче камырдан әзерлиләр. Эченә бәрәңге боламыгы, тары боткасы, төйгән киндер орлыгы яки мәк орлыгы салалар.**

«Кыстыбый» сүзе татар теленнән күрше халыкларның телләренә дә кергән. Мәсәлән, башкортча «кыстыбай», чувашча – «кескелай», мариларда – «кыстывий», удмуртча – кыстыбей.

Кайбер төбәкләрдә шундый гореф-гадәт тә саклана: һәр җомгада, бер ел тулганчы, кызның ата-анасы кияү белән кызны кыстыбый пешереп кунакка чакыра.

Татархanә

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Мастер-классны «Тәмле булсын» ресторannар челтәре җитәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** алып бара

# КЫСТЫБЫЙ






Резидә Хөсәенова һәм Татарстанның атказанган артисты Динә Латыйпова



## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**
300 грамм он,
2 данә йомырка,
200 грамм кефир яки сөт,
1-2 аш кашыгы көнбагыш мае,
бер чеметем чәй содасы һәм
тәменчә тоз.

**Эчлек өчен:**
1 килограмм бәрәңге,
200 грамм атланмай,
1 данә суган,
200-250 грамм сөт яки сөт өсте,
тәменчә тоз.



**1** Кыстыбыйның камырын ясарга керешкәнче, аның эченә салыначак бәрәңгесен пешерергә куябыз. Чистартылган суганны вак кына итеп турыйбыз һәм алтынсу төскә кергәнче майда кыздырабыз. Бәрәңге пешеп чыккач, суын түгеп, 100 грамм атланмай, кайнаган сөт, кыздырылган суганны салып, изәбез.





**2** Савытка 250 грамм кефир яки сөт, ике йомырка, чеметеп кенә тоз, чәй содасы һәм 1-2 аш кашыгы көнбагыш мае салып туглыйбыз. Он өстәп, йомшак кына камыр басабыз.





**3** Камырны 75әр граммлы кисәкләргә бүлеп, юка гына итеп җәябез. Бертөрле җәемнәр килеп чыксын өчен, җәелгән камыр өстенә тәлинкә куеп, махсус кискеч белән кисәбез.






4 Киселгән әзер җәемнәрне ике ягын да коры, кызган табада пешереп алабыз. Пешкән җәймәләрне, берсе өстенә берсен өеп, кибеп сынмасын өчен, тастымал белән каплап куябыз.





5 Пешкән җәймәләрнең ике ягын да эретелгән атланмай белән майлыйбыз. Чама белән җәймәнең яртысына 7-8 миллиметр калынлыкта әзер эчлекне (безнең очракта бәрәңге боламыгын) ягып, тиз генә икенче ягы белән каплап куябыз. Әзер кыстыбыйларны тәлинкәгә өя барабыз.



6 Кунакларга кыстыбыйны тәлинкәгә салып, чәй яисә сөт белән бирәбез.

АШЛАРЫГЫЗ ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
# 2024

## АПРЕЛЬ

**1 апрель**

Язучы, журналист, филология фәннәре кандидаты Константин Константинович Петровның тууына 100 ел (1924-2007)

**3 апрель**

Рәссам Наталия Константиновна Винниковага (Бенингка) 60 яшь (1964)

**8 апрель**

Сынчы Владимир Андреевич Демченкога 75 яшь (1949)

**10 апрель**

Рәссам Ирек Наил улы Массаровка 70 яшь (1954)

**15 апрель**

Язучы, Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Самат Фәтхерахман улы Шакирның (Шакиров) тууына 100 ел (1924-1998)

**16 апрель**

Актриса, Татарстан АССРның атказанган артисты Зәйнәп Галиәкбәр кызы Камалованың тууына 125 ел (1899-1977)

**17 апрель**

Рәссам Азат Сибгатулла улы Газизуллинга 60 яшь (1964)

**20 апрель**

Рәссам Альберт Маратович Шинибаевка 50 яшь (1974)

**26 апрель**

Артист Фәнис Кәбирҗан улы Сафинга 50 яшь (1974)

## МАЙ

**5 май**

Фольклорчы галим, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәмит Хөснетдин улы Ярминең (Ярмөхәммәтев) тууына 120 ел (1904-1981).

**8 май**

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, шагыйрь, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Равил Фәйзерахман улы Рахманига (Кукушкин) 75 яшь (1949)

**8 май**

Актриса, Татарстан Республикасының халык артисты Сания Каюмҗан кызы Каюмовага 70 яшь (1954)

**14 май**

Рәссам, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.И. Урманче исемендәге премиясе лауреаты Зөфәр Сәет улы Низаметдиновка 75 яшь (1949)

**19 май**

Җырчы, педагог, театр эшлеклесе, Татарстан АССРның һәм РСФСРның халык артисты Мөнирә Закир кызы Булатованың тууына 110 ел (1914-2011)

**24 май**

Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Хәмдүнә Сәетгали кызы Тимергалиеваның тууына 75 ел (1949-2020)

## ИЮНЬ

**3 июня**

Артист Илһам Нәҗип улы Шәйдуллинга 50 яшь (1974)

**5 июнь**

График, рәссам, Бөек Ватан сугышында катнашкан Хаҗиморат Исхак улы Казаковның тууына 110 ел (1914-1984)

**6 июнь**

Рус шагыйре Александр Сергеевич Пушкинның тууына 225 ел (1799-1837). 1833 елның сентябрендә Казанда булып китә

**12 июнь**

Рәссам Әбүзәр Рәүф улы Габдрахмановка 70 яшь (1954)

**13 июнь**

Рәссам, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Илдус Хаҗи улы Мортазинга 60 яшь (1964)

**13 июнь**

Рәссам-ювелир Шамил Касыйм улы Хәялиевка 60 яшь (1964)

**16 июнь**

Җырчы, Татарстан АССРның халык, РСФСРның атказанган артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәйдәр Аббәс улы Бигичевның тууына 75 ел (1949-1998)

**16 июнь**

Дәүләт һәм хакимият-хуҗалык эшлеклесе, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Татарстанның Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Готыф улы Әхмәтовка 70 яшь (1954)

**17 июнь**

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры ачылуга 85 ел (1939)

**24 июнь**

Рәссам Елена Геннадьевна Остраяга 60 яшь (1964)

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды

**Кадерле укучыларыбыз!**
2024 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.

**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 294 сум 07 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 588 сум 14 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!

